УРАК ӨСТЕ
Президент районнарда урып-җыю барышын күреп кайтты
> 2

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ
Татарстан Президенты имзалаган яңа законнар
> 3-4

УКУ ТӘМЕ
Язучы Марат Кәбиров электрон китап белән кәгазь басмадан кайсын сайлый?
> 5

МИЛЛИ КИЕМ
Казанда «Печән базары»ның унынчысы гөрләде
> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 110 (28883) | Сишәмбе | 2 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Гөлгенә ШИҺАПОВА

БУРЫЧКА ЯШӘҮ

Яшәргә өйрәнәбез

Татарстанда торак-коммуналь хезмәтләр өчен әҗәтен түләмәүчеләр артканнан-арта бара. Күп кенә йортларның подъездына бурычлары булган кешеләрнең исем-фамилияләрен дә язып эләләр. Татарстан Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 1 июльгә булган мәгълүматларына караганда, республика халкының коммуналь хезмәтләр өчен 8,79 млрд сум әҗәте җыелган. Түләмәүчеләр кемнәр? «ВТ» журналисты әнә шуны ачыкларга тырышты.

– Кешеләрнең пандемия аркасында тормыш хәле катлауланды, – ди Казанда бер идарәче оешмада техник-инженер булып эшләүче Гөлсинә Миңнебаева. – 2020 елда күп кенә кешеләр эшсез калды. Авырып китүчеләре, эчүчелеккә сабышучылары да бар иде. Мин еш кына түләмәүчеләрнең өйләренә барып йөрим, алар белән уртак тел табарга тырышам. Әмма кайчак аларны кызганып, елап та кайтам.

Хәер, үзебез яшәгән йортта да бар ул түләмәүчеләр. Эзләп тә азапланасы юк. Беренче катта белдерүләр тактасында исемнәре эленеп тора. Арадан берсе белән сөйләшеп тә йөрибез. Язма әзерләргә кирәк булгач, әкрен генә кылларын тарттым. Ә аңа шул гына кирәк тә булган. Эчендәге бар хәсрәтен, борчуын түкми-чәчми сөйләп бирде.

– 2010 елда ирем һәм ике балабыз белән социаль ипотекага фатир алып күчендек. Ирем башта ук, иң элек кредитын түлибез, аннары коммуналь хезмәтләрен капларбыз, диде. Тик минем бәхетсезлегемә, 2020 ел ахырында үпкәсендә яман шеш булып, ирем үлеп китте. Бик авыр хәлдә калдым. Әле ярый, туганнарым ярдәм итеп, кредитны ябып бетердек. Ә коммуналь хезмәт өчен бурыч өелеп калды. Иремнең машинасын сатып, мин аның бер өлешен түләгән дә идем инде. Әмма тагын 180 мең сум бирәсем бар әле, – ди Гөлия Шакирҗанова. – Бер теләк: урамда гына калдырмасыннар.

Урам дигәннән, соңгы арада берәүне дә фатирыннан куып чыгаручы юк икән. Андыйларны кечерәк фатирга күчерү тәҗрибәсе бар. Күп очракта зур фатирны кечерәккә, хәтта тулай торак бүлмәсенә дә алыштыралар. Фатирны сатып, бурыч түләүчеләр дә бар.

– Күп кенә түләмәүчеләргә ай саен пеня өстәлә, димәк, бурыч тагын арта, – ди «Мой дом» идарәче оешмасы хезмәткәре. – Эше булган, уйлап эш йөрткән кеше аны вакытында түли. Әгәр ике ай түләмиләр икән, без андыйларны судка бирәбез. Кешене башкача өйрәтеп булмый. Күпләр судка чакыру кәгазе килгәч кенә йөгерә башлый. Күп еллар күзәтәм: акчасы булмаган, бер пенсиягә яшәүче өлкәннәр иң элек коммуналь хезмәтләр өчен түләп куя. Ә хәзерге буын артык аптырамый. Бурычлары күпме җыелганны да белмәүчеләр бар. Күпләр чит илгә җыенганда гына бу хакта исенә төшерә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Чит ил дигәннән, кешеләрнең диңгез күрү теләге шулкадәр көчле: алар нәкъ менә сәфәр алдыннан бурыч каплый башлый икән. Бу хакта шушы көннәрдә Казанда Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең алты айлык эшчәнлегенә нәтиҗә ясаган коллегиясендә дә әйттеләр. Әҗәтләрне кайтартып алу өчен, бурычлыларның мөлкәтенә, банк карталарына арест салына. Хезмәт хакының күпмедер өлеше дә тотып калынырга мөмкин. Милек рәсмиләштерүгә рөхсәт бирмәү, Россиядән чыгуны тыю һәм административ җаваплылыкка тарту да каралган. Быелның алты аенда суд приставларында торак-коммуналь хезмәтләргә кагылышлы 35649 производство эше теркәлгән. Шуларның 7163е уңай хәл ителеп, 323 миллион сумнан артык акча кайтарылган. Суд приставлары бурычлыларның машиналарын да ала. 160 мең сумнан артык әҗәте җыелган ир-атка карата шундый чара күргәннәр. Тиз арада бурычын ябып, машинасын килеп алган.

Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәгенең әйдәп баручы белгече Любовь Лапаева бурычны вакытында түләргә, аны җыеп тормаска киңәш итә. Кайберәүләр, бу хезмәт миңа кирәкми, түләмим, дип махсус түләми икән.

– Безгә күбрәк квартплата кәгазендәге суммадан риза булмаучылар килә. Аларга мөмкин кадәр ярдәм итәргә тырышабыз. Ә менә бурычлы кешегә без берничек тә ярдәм итә алмыйбыз. Кайвакыт җәйге айларда фатирда тормадым дип 10–15 мең сум бурыч җыйган кешеләр килә. Кайчак 300–400 мең сум әҗәте җыелганнар да очрый. Әле менә берәү килде. 800 мең сум бурычы бар. Әлеге кеше үзенә килгән суммалар белән килешмәгәч, түләп тормаган. Түләмәгәч, пеня җыелган. Шулай итеп, бурыч артып кына торган, – ди Любовь Лапаева. – Капиталь төзекләндерү миңа кирәкми дип, шушы хезмәт өчен еллар буе махсус түләмәүчеләр дә шактый. Болай итү дөрес түгел инде.

Любовь Лапаева, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түли алмасаң, нишләргә икәнен дә аңлатты.

– Хәзер бурычларны кайтару белән коллекторлар түгел, идарәче оешма шөгыльләнә, – диде ул. – Кеше матди хәле аркасында түли алмый икән, шундук идарәче оешмага барып, бу хакта аңлатып, гариза язып калдырырга тиеш. Аның хәленә кереп, пеналар өстәмиләр. Әҗәт җыелган икән, бу очракта да идарәче оешмага барып, сумманы үзеңә уңайлы итеп түләү өчен килешү төзеп була. Сиңа хәзерге ай түләве һәм җыелган бурычның үзең сайлаган түләрлек суммасын исәпләп җибәрә торган булалар. Болай эшләү тагын да күбрәк әҗәт җыелмаудан саклый. Бурычлыларны идарәче оешма 20 көн алдан кисәтеп куярга тиеш. Аннары өенә килеп, утны өзә һәм су китү юлларын яба. Әлбәттә, бу бик күңелле хәл түгел. Мондый хәлләргә тарымас өчен, вакытында түләргә кирәк.

Төзиләр һәм яңарталар

Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә яңа уку елына әзерләнү турында сөйләштеләр. Республикада барлыгы 1413 мәктәп һәм 98 урта һөнәри белем бирү оешмасы эшләячәк. Хәзерге вакытта федераль һәм республика программалары кысаларында 13 мәктәп (барлыгы 10283 урынга) төзелеп килә. Сигезен (7203 урын) 1 сентябрьгә кадәр төзеп бетерү күздә тотыла. Өчесе (355 урын) ел ахырында әзер булачак.

Моннан тыш яңа уку елына 118 мәктәп бинасында (66сы – федераль программа буенча) төзекләндерү эшләре төгәлләнергә тиеш. Алты урта һөнәри белем бирү оешмасында ресурслар үзәкләрен капиталь төзекләндерү программасы нигезендә эшләр оештырылган.

Искесе үткәндә калды

Казанның Балалар йогышлы авырулар хастаханәсе Окольная урамындагы иске бинадан Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе (РКИБ) дәвалау бинасына күчте. Биредә капиталь төзекләндерелгәннән соң балаларга махсус медицина ярдәме күрсәтү бүлеге ачылды.

Төзекләндерү эшләре, республика бюджеты хисабына, РКИБны яңарту кысасында башкарылды. Хастаханәнең палаталары, электр, җылылык белән тәэмин итү челтәрләре төзекләндерелде. Яңартылган бүлек балаларга медицина ярдәме күрсәтү өчен кирәкле заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән.

Йогышлы авырулар хастаханәсенең дәвалау корпусын яңарту эшләре Окольная урамындагы клиника хезмәткәрләрен тулысынча бирегә күчерү мөмкинлеге бирде. 1968 елда төзелгән, 110 ятаклы бина инде заманча санитар-эпидемиологик нормативлар таләпләренә туры килми иде. Балалар клиникасын РКИБның дәвалау корпусына күчерү шулай ук штат расписаниесен уңайлырак итүгә, медицина ярдәме мөмкинлеген үстерүгә китергән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ана капиталы белән түлиләр

Студентларның ата-аналары балаларын укытуга ана капиталы белән түли ала. 2007 елдан республикада яшәүчеләрдән 35,5 меңнән артыграк шундый гариза кергән инде. Бу акчаны институтта яки көллияттә белем алу өчен тотарга мөмкин. Баланы ана капиталы хисабына укыту турында гаризаны, Пенсия фондына мөрәҗәгать итмичә, шәхси компьютер яки смартфон аша гына да юлларга мөмкин.

Белем алуга ана капиталын тоту өчен өч шартны үтәргә кирәк. Беренчедән, студентның яше 25тән артмаска тиеш. Икенчедән, мәгариф оешмасының Россиядә урнашып, белем бирүгә хокуклы булуы кирәк. Өченчедән, ата-ана икенче баласы туганнан соң бирелгән сертификатны беренчесен укытуга тотарга уйласа, төпчеккә 3 яшь тулуын көтү зарури. Баланы укытуга ана капиталын тоту турында гаризаны Россия Пенсия фонды сайтындагы шәхси кабинет аша, шулай ук Пенсия фондының клиентлар хезмәтенә яисә Күпфункцияле үзәккә барып тапшырырга мөмкин.

COVID-19

Уйланыр чак

Вакцинасы да, саклану чаралары да кирәк. Белгечләр коронавирус белән чирләмәс өчен нәрсә эшләргә икәнен кабат сөйләргә тотынды. Соңгы арада вазгыять тынычланырга иртәрәк булуын искә төшерә башлады чөнки.

Хөкүмәт йортындагы «шимбә киңәшмәсе»ндә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та коронавирустан саклану чараларының әһәмияте турында сөйләде.

– Республикада инфекциягә каршы тотрыклы күмәк иммунитет булдыру мөһим. Бигрәк тә чир йоктыручылар арткан вазгыятьтә, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент искәрткәнчә, узган атнада коронавирус белән авыручылар саны 8 процентка арткан. Моңа өстәп, күмәк иммунитет күрсәткече дә кими. Саннарга килгәндә, хәзерге вакытта Татарстанда коронавируска каршы вакцинаны 2 млн 591 мең кеше ясаткан. Икенче дозасын 2 млн 464 мең кеше алган.

Моңа карап кына тынычланырга ярамый. Президент ревакцинациянең әһәмияте турында да әйтте.

– Безгә республикада тотрыклы күмәк иммунитетны саклау мөһим. Кабат вакцина ясату буенча эшне активлаштырырга кирәк. Тынычланырга ярамый, чир беркая да китмәде. Без чит илләрдә дә, Россиядә дә, республикада да авыручылар саны артуын күрәбез, – диде Рөстәм Миңнеханов. – COVID-19 чиреннән сакланунының ике юлы бар: вакцина ясату һәм санитар кагыйдәләрне үтәү. Медицина оешмалары битлек кию режимын кабат кайтарды. Безгә дә бу җәһәттән киңәшләшәсе булыр. Әлбәттә, җәен уңайсыз нәрсә инде ул. Әмма вазгыять шулай барса, бу чаралар кирәк булачак.

Сүз уңаеннан, вирусның кабат баш калкытуына карамастан, ил халкы битлек режимын кире кайтару яклы түгел. SuperJob хезмәте оештырган сораштыру нәтиҗәләренә күз салсаң, халыкның 48 проценты битлек кию режимына каршы чыккан. 23 проценты кабат битлектән йөрү зыян итмәс иде дигән фикердә тора.

Вакцина димәктән, соңгы арада төбәкләрдә халыкның «Спутник Лайт» вакцинасының юклыгыннан зарлануы ишетелде. Әмма Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы тынычландыра: вакцина табу – проблема түгел. Министрлыкның йогышлы авырулар буенча штаттан тыш баш белгече Владимир Чуланов белдергәнчә, төбәкләрдә ике компонентлы «Спутник V» вакцинасы запасы җитәрлек. Мәгълүм булганча, аның беренче компоненты «Лайт»ка тиңдәш.

– Моннан алты ай элек вакцина ясаткан һәм ревакцинация узган кешеләргә, кагыйдә буларак, авыруны җиңел кичерүгә карамастан, кабат вакцина ясатырга киңәш ителде. Бу бигрәк тә дөньяның күп кенә илләрендә, шул исәптән Россиядә коронавирус инфекциясе белән авыручылар санының артуын исәпкә алганда, бик мөһим, – диде ул.

Сан

- Соңгы мәгълүматлар буенча, Россиядә **12498** кеше коронавирус йоктырган. **982** кеше, чир йоктырып, хастаханәгә эләккән. Сүз уңаеннан, илнең **17** төбәгендә госпитализация саны арту, **62**сендә кимү күзәтелә. Алты төбәктә хәл үзгәрешсез кала.
- Бер тәүлек эчендә ил буенча **6056** кеше дәваланып чыккан.
- Татарстанда коронавирус белән авыруның **35** очрагы теркәлгән.

Сүзгә-сүз

Илсур ҺАДИУЛЛИН, Татарстанның мәгариф һәм фән министры:

Укытучы һәм остаз елында бетмәс-төкәнмәс чаралар белән мөгаллимнәребезнең башын катырмаска тиешбез. Балалар белән күбрәк шөгыльләнә алсыннар өчен тынычлыкта калдырсак, алар өчен бу чын бәйрәмгә әйләнәчәк. Ә инде төрле чаралар үткәрергә, шуннан соң хисап тотарга, әллә нинди шоулар оештырырга мәҗбүр итә башласак… Чамасын белергә кирәк.

(«Татар-информ»)

РОССИЯДӘ – УРТА СЫЙНЫФ

РИА рейтинг белгечләре ил төбәкләрендә яшәүчеләрнең күпме өлеше тормыш дәрәҗәсе буенча урта сыйныфка кергәнен ачыклаган. Урта сыйныф дип автомобиль яки фатир сатып алу, ялга бару мөмкинлегенә ия булган, айлык кредит бурычын каплагач, гаиләдәге һәр кешегә төбәктәге ким дигәндә ике яшәү минимумы күләмендә акчасы калган, күпмедер мая туплый алган гаиләләр санала.

Урын	Төбәк	Урта сыйныфка кергән гаиләләр %
1	ЯНАО	46,6
2	Магадан өлкәсе	37,1
3	Чукотка АО	33,1
...		
8	Мәскәү	24,4
...		
10	Санкт-Петербург	21,2
...		
35	**Татарстан**	**9,4**
...		
85	Чечня	1,5

Акча сурәтен сайлыйлар

Яңартылган 1000 сумлык акчада Казан Кремле сурәте пәйда булырга мөмкин. Яңа меңлек өчен сурәтләр исемлегенә Татарстаннан берничә корылма кертелгән. Үзәк банк рәисе урынбасары Сергей Белов әйтүенчә, яңа 1 һәм 5 меңлек акчаларның идеясе расланган. Хәзерге вакытта рәсемнәренең караламалары эшләнә. Белгечләр акчада сурәтләнергә мөмкин булган 30га якын мөһим корылманы тәкъдим иткән. Финалга Казан Кремле, Сөембикә манарасы, «Казан» гаилә үзәге, «Болгар шәһәрлеге» тыюлыгы чыккан. Шулай ук Түбән Новгородтан берничә объект: Кремль, Чкалов баскычы, Түбән Новгород ярминкәсе бинасы, Максим Горький һәйкәле тәкъдим ителгән.

Яңартылган 1000 һәм 5000 сумлыклар – киләсе елда, 500 сумлык – 2024 елда, 10 һәм 50 сумлыклар 2025 елда әйләнешкә кертеләчәк.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТАЙВАНЬМЫ, КОСОВОМЫ: КАЙДА УЧАК ЯГАРЛАР?

Үткән атна нервларны соңгы чиккәчә киеренкелеккә китергән зур вакыйгалар белән тәгәлләнде. Планета халкының сәяси яктан актив өлеше әнә-менә Өченче Бөтендөнья сугышына тиң конфликтка старт бирелә дип көтте. Хәл, чынлап та, җитди иде, чөнки зур чатнау нәтиҗәсендә Көнчыгышта да, Көнбатышта да глобаль икътисади кризис зур ярыклар хасил итәргә җыена.

Шимбә кичендә АКШ конгрессының вәкилләр палатасы спикеры Нэнси Пелоси – Вашингтондагы хакимият пирамидасындагы өченче дәрәҗәдәге зат – Азия илләренә рәсми сәяхәт ясау өчен, самолетка утырып, күккә күтәрелде. Сәясәтченең Кытай Тайванена да рәсми визит белән тукталыш ясарга нияте булу турында хәбәрләр алдан ук таратылды. Пекин, андый визит була калса, кискен чаралар күрәчәген игълан итте, Көньяк Кытай диңгезендә масштаблы хәрби өйрәнүләр башлады, Тайваньга иң якын булган Фуцзянь провинциясенә калканлы техника агылды, Тын океанның Тайвань бугазы акваториясен япты. Газета хәбәрчесе Кытай Халык Азатлык армиясенең 72 бригадасы карамагындагы Harbin Z-19 вертолетларының һавага күтәрелүен онлайн режимда таң калып күзәтте: күктә иксез-чиксез булып тоелган армада чайкала иде. Пекин тарафыннан Пелоси утырган самолетны бәреп төшерү турында рәсми хәбәрләр яңгырады. Регистрация номеры 09-0540 булган Boeing C-40C очышына дистә меңләгән кеше Flightradar сайтында (күктәге һәрбер очкычның хәрәкәтен шул сайт аша күзәтеп торып була) реаль режим вакытында текәлде. Очкыч Гавайга төшеп утыра башлагач, барыбыз да җиңел суладык. Әмма тукталыш ягулык салу өчен генә булырга мөмкин иде, шуңа күрә киеренкелек дәвам итте. Төбәккә «Рональд Рейган» очкыч йөртүче корабы җитәкчелегендәге Америка хәрби флоты төркеме дә юл алды. Тайвань да Han Kuang кодлы исем белән хәрби өйрәнүләр башлаган һәм аз гына ялгыш хәрәкәт тә Бөтендөнья фаҗигасенә тиң драмага старт бирергә ихтимал иде. Кытайның да, Тайваньның да һава һөҗүменә каршы тору чаралары сугыш хәленә китерелеп җәелдерелде.

Якшәмбе кичендә Көнбатышта яңа сугышка старт бирә яздылар. Сербия – Косово чигендә кораллар чыңлады. Сербия ике ил арасындагы чиккә регуляр армиясен һәм хәрби һава көчләрен тупларга тотынды. Ил Президенты Александр Вучичның, Косовода сербларны кыссалар, Сербиянең һөҗүм башлаячагы һәм җиңәчәге турында мөрәҗәгате яңгырады. Косовоның да төньяк муниципалитетларында мобилизация игълан ителү турында хәбәрләр күренде. Эш шунда: Косово хакимиятләре үзләренә килгән сербларның документларын танымаулары, аларга махсус Косово документлары бирәчәкләрен әйткәннәр иде. Яңа тәртип 1 августтан гамәлгә керәсе булганга, зур янгын чыгара яздылар да инде. Әмма АКШның Приштинадагы илчесе яңа тәртипне 1 сентябрьгә кадәр кертми торырга үтенгәч, ут чыгарырга тиешле очкынны әлегә сүндереп тордылар. Сербия – Россия тарафдары, Косово исә Көнбатышны гәүдәләндерә. Сугыш чыга калса, эш зурга китәргә мөмкин иде.

Россиядә

ЯҢА ДИҢГЕЗ ДОКТРИНАСЫ

Россиядә быел Хәрби диңгез флоты көне масштаблы сәяси вакыйга булып тарихка кереп калды. Традиция буенча Владимир Путин Санкт-Петербургта Төп хәрби диңгез парадын кабул итте. Президентның Петропавел крепостенда яңа Диңгез доктринасын имзалавы Россиянең милли мәнфәгатьләрен киңрәк җәелдерү омтылышы буларак бәяләнде.

Доктринада АКШның өстенлеккә омтылуы һәм НАТОның активлыгы үсү Россиянең милли куркынычсызлыгы өчен төп янау дип игълан ителде. «Милли мәнфәгатьләр» дигән яңа бүлек пәйда булды. Арктик зона һәм Төньяк диңгез юлы милли мәнфәгатьләрнең өстенлекле өлеше буларак карала. Кара һәм Азов диңгезләре акваториясе, Урта диңгезнең көнчыгыш өлеше Россиянең милли мәнфәгатьләрен тәэмин итүче зоналар буларак таныла. Кырымдагы һәм Краснодар краендагы Кара диңгез флоты көчәйтеләчәк. Һинд океаны һәм Фарсы култыгында илнең хәрби куәтләре арттырылачак. Суднолар төзегәндә, очкыч йөртүче кораблар (авианосецлар) төзү өстенлекле юнәлешкә әвереләчәк. Әлегә Россиянең бары тик бер генә очкыч йөртүче хәрби корабы бар, анысы да бик иске һәм эшкә ярарлык хәлдә түгел. Яңа авианосецлар төзү – бик кыйммәткә төшә торган шөгыль. Бик куәтле державаларның җилкәсе генә аны күтәрә ала. Кызыл диңгездә һәм Һинд океанында Хәрби диңгез флотының матди-техник тәэмин итү пунктларын булдыру да күп акча сорый һәм яңа конфликтлар китереп чыгарырга ихтимал.

Доктринадагы Шпицберген, Франц Иосиф җире, Яңа Җир архипелагларында һәм Врангель утравында хәрби диңгез активлыгын арттыру турындагы ниятләр дә шул төбәкләргә якын дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрне катлауландырачак. Шпицбергенның яңа документта телгә алынуы очраклы түгел. Бу – Норвегия белән бәйле төбәк. Күптән түгел генә норвеглар ул архипелагтагы россиялеләргә йөк ташуга аяк чалдылар. Проблема ахыр чиктә чишелде, әмма Норвегия белән Россия арасында дошманлык пәйда була башлады. Эш шунда: 2010 елда Россия – Норвегия чикләре турында килешү имзаланган иде. Ул вакыттагы Президент Дмитрий Медведев Баренц диңгезе акваториясенең бер өлешен Ослога бирде. Соңыннан норвеглар ул төбәктә бик бай углеводород ятмалары таптылар. Россия сәясәтчеләре арасында 2010 елгы килешүне зур оттыру буларак бәяләүчеләр табылды. Хәзер алар ул килешүне гамәлдән чыгарырга өнди.

Шпицбергенда барысы дүрт йөзләп россияле яши. Норвеглар быел, санкцияләрне сылтау итеп, шуларга товар ташуны тыймакчы булдылар. Ахыр чиктә йөк йөртүне норвег корабларына тапшырып, шуларның катгый контролендә генә диңгез элемтәсе булдыру турында килешүгә ирештеләр. Архипелагка бәйле 1920 елда төзелгән Париж килешүе дә бар. 1947 елда Норвегия СССРның архипелагта икътисади мәнфәгатьләре барлыгын таный. Шпицбергенга бәйле тагын берничә халыкара документ бар әле. Менә шундый катлаулы төбәк яңа Диңгез доктринасына кертелде.

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:

«ХӘЗЕР ИҢ КИЕРЕНКЕ ВАКЫТ»

Көннәрнең кояшлы һәм җылы торуына игенчеләр сөенә, чөнки урып-җыю чорында һәр минут кадерле. Өлгергән уңышны вакытында җыеп алып, амбарларга кайтарып җиткерәсе бар. Җаваплы эшкә тотынучы районнар саны көннән-көн арта, димәк, урып-җыю кампаниясе кызулыгын арттыра. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының оператив мәгълүматлары буенча, дүшәмбегә 7536 гектар мәйданда 33 мең тоннага якын ашлык җыеп алынган.

Татарстан Хөкүмәте йортында узган киңәшмәдә дә урак турында сөйләштеләр. Президент Рөстәм Миңнеханов быел көзге уңышны сыйфатлы һәм оператив җыеп алырга кирәклеген әйтте. Эш мөмкин кадәр кыска вакыт эчендә һәм югалтуларсыз узсын өчен, лаеклы хезмәт хаклары түләргә һәм кыр эшләре алдынгыларына кызыксындыру чараларын күрергә кирәклеген белдерде, дип хәбәр итә Президентның матбугат үзәге.

– Кызыксындыру җитди булырга, кешеләр акча эшләргә тиеш. Без моның хисабына күбрәк уңыш алачакбыз. Комбайнчы хезмәте бик авыр. Механизаторларның ике сменалы эшен оештырырга, аларны вакытында кайнар аш белән тәэмин итәргә кирәк, – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, быел барлыгы 1,5 миллион гектар мәйданда бөртекле һәм кузаклы культуралар, 427 мең гектарда май культураларын җыеп алырга кирәк. Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә 3417 комбайн эшләячәк. Соңгы өч елда Татарстанда техниканың 20 проценты яңартылган, 635 яңа комбайн сатып алынган. Быел исә предприятиеләр 104 берәмлек техника алган. Шулай ук техниканы читтән җәлеп итү эшенә дә игътибар бирергә кирәклеген әйтте Президент.

Ял көнне исә Рөстәм Миңнеханов Нурлат, Яңа Чишмә, Аксубай районнарында булып, урып-җыю барышын бәяләде, игенчеләр белән очрашты һәм авыл хуҗалыгы объектларын карады. Нурлат районы башлыгы Алмаз Әхмәтшин сүзләренчә, аларда урып-җыю узган атнада башланган. Ял көненә 2700 гектар суктырылган, 10 мең тоннага якын яңа уңыш (арпа һәм көзге бодай) җыеп алынган, уртача уңыш гектарыннан 42 центнерны тәшкил итә. Барлыгы 40 мең га мәйданда җыеп аласы бар. Шул ук вакытта хуҗалыклар көзге культуралар чәчүгә туфрак әзерләүне дәвам иттерә.

Нурлат районында барлыгы 12,1 мең шәхси ярдәмче хуҗалык исәпләнә. Шулай ук быел 12 яңа мини-ферма төзелә.

– Безгә терлекләрнең баш санын саклап калу, санын арттыру мөһим. Сөткә дә игътибар бирергә кирәк. Сөт ул – авыл халкы өчен тотрыклы хезмәт хакы чыганагы. Хуҗалыкларда һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларда терлекләрнең баш санын ничек арттыру турында уйларга кирәк. Төрле кызыксындыру чаралары кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов. Ул агросәнәгать комплексы секторына инвесторларны активрак җәлеп итәргә, эшкәртүгә зур игътибар бирергә, азык запасы булдырырга кушты.

tatarstan.ru

Авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров әйтүенчә, Нурлат районы бүген авыл хуҗалыгы нәтиҗәлелеге рейтингы буенча 27 нче урында тора. Аңлашыла инде, өскәрәк күтәреләселәре килә. Районда терлекчелек юнәлешендә берничә проект тормышка ашырыла. Өстәвенә районда сөт сатып алу бәяләре дә яхшы: килограммы – 29 сум.

– Нурлат районы – республикада алдынгыларның берсе. Сезнең резервлар зур. Алардан дөрес итеп файдаланырга кирәк, – диде Татарстан Президенты.

Шулай ук ул комбайнчылар белән аралашты, хезмәт шартлары һәм кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләре белән кызыксынды.

– Бүген иң киеренке вакыт. Узган ел бик катлаулы булды. Хәзер уңышны җыеп алу да, терлек азыгы әзерләү дә мөһим. Эшләрегез яхшы барсын, – дип теләде ул.

Аннары Президент ит һәм сөт эшкәртүчеләр, теплица хуҗалыклары, икмәк салу, умарта, балыкчылык хуҗалыклары продукциясе күргәзмәсен карады. Шуннан соң Нурлат ат заводының ат спорты манежында булды.

Президент сәфәренең икенче тукталышы Яңа Чишмә районы иде. Биредә дә ул урып-җыю барышы белән кызыксынды. Игенчеләр әйтүенчә, районда 58 мең гектардан уңыш җыеп алырга кирәк булачак. Моның өчен 69 комбайн җәлеп ителәчәк, шул исәптән читтән дә. Әңгәмә барышында Президент терлекчелекне актив үстерү кирәклегенә басым ясады. Шуннан соң аңа заманча ашлык киптерү комплексын күрсәттеләр.

Аксубай районында да ул район кырлары, кайбер авыл хуҗалыгы объектлары белән танышты, шулай ук игенчеләр һәм авыл җирлеге башлыклары белән очрашты. Бүген район басуларында 99 комбайн эшли, аларның 30ы читтән килгән.

– Бүген иң мөһиме – сыйфатлы урып-җыюны оештыру һәм туфракны көзге чәчүгә әзерләү. Терлек азыгы үзәкләрен үстерү буенча эшләргә кирәк, – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов.

Аннан соң Президент «Волга-Селект» хуҗалыгының эремә ясау узелы белән танышты. Стационар комплекста чәчүлекләрне тукландыру, аларны корткычлардан һәм чүп үләннәрдән саклау өчен су әзерлиләр. Шуннан соң Президент төзелеп килүче ашлык киптерү комплексын һәм орлык заводын карады. Базада 7 мең тонна бөртекле культуралар сакланачак. Орлык линиясе сәгатенә 10 тонна орлык җитештерергә мөмкинлек бирәчәк.

ТИЗ ТӨЗИЛӘР, КЫЗУ ЙӨРИЛӘР

Россия тарихында иң тиз төзелгән автомагистраль булачак. Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин яңа төзелүче М12 Мәскәү – Казан трассасына шундый өметләр баглый. Күптән түгел РБК порталына биргән әңгәмәсендә шулай дип белдерде ул. Аңа кадәр вице-премьер Россия Президенты Владимир Путин белән очрашуда да яңа трассаның төзелеш барышы турында сөйләгән иде.

tatarstan.ru

Һавадан алып әйтелгән сүзләр түгел бу. Хөснуллин сүзләренә караганда, трасса төзелеше планлаштырганнан да тизрәк бара. Беренче чакрымнарны бу ел азагына ук тапшырырга җыеналар. «Әлеге Мәскәү – Казан – Екатеринбург трассасын 1,5 ел элек төзи башладык. Беренче 95 чакрым юлны планлаштырганнан бер ел алдан – быел ук тапшырырга мөмкинбез. Көтелмәгән хәлләр килеп чыкмаса, ел азагына инде трасса төзелешенең өч этабын ук йомгаклаячакбыз», – диде Марат Хөснуллин Путин белән очрашуда. Монда трассаның Мәскәү һәм Владимир өлкәсендәге өлешләре турында сүз бара.

«Бар да без уйлаганча барса, Россия тарихында иң тиз төзелгән автомагистраль булачак бу. 2,5 елда 3830 чакрым юл төзеләчәк», – ди Хөснуллин. Яңа М12 трассасы буйлап Мәскәүдән Казанга 6,5 сәгать эчендә кайтып булачак. Вице-премьер сүзләренә караганда, киләчәктә әлеге трасса Омск белән Новосибирскига кадәр озайтылырга да мөмкин. Бу исә Кытай һәм Монголия чигенә кадәр барып җитәргә мөмкинлек бирәчәк.

Яңа трасса түләүле булачак. Әмма әлегә төгәл саннар аталмый. Яңа юлдан җилдергән өчен кесә янчыгын күпмегә юкартырга туры киләчәге дә билгесез. Марат Хөснуллин сүзләренә караганда, трассаның төрле участогында бәяләр төрлечә булачак. «Владимирдан Мәскәүгә һәм Мәскәүгә керү юлларында йөрү күпкә кыйммәткәрәк төшәчәк, билгеле. Алга таба трассаның, әйтик, шул ук Түбән Новгородка, Чабаксарга илтүче өлешләрендә чакрым хаклары күпкә арзанрак булачак. Казан тирәсендә исә алар кыйммәтрәк йөриячәк», – ди вице-премьер.

Яңа трассада йөрүнең күпмегә төшәчәге турында узган атнада Татарстанның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов белән «туры элемтә» вакытында да сүз булды. Министр сүзләренә караганда, яңа трасса төзелеше турында әле фикер алышулар гына алып барылган чорда биредәге бер чакрым юл 2 сумга төшәчәк дип фаразланган булган. «Әмма республика халкына трассаның Татарстандагы өлеше буйлап хәрәкәт итү бушлай булачак», – ди Фәрит Хәнифов.

М12 трассасында акча җыеп торучы киртә, шлагбаумнар булмаячак дип ышандыралар. Аның урынына биредә махсус сканерлар урнаштырылачак. Алар 13,1 миллиард сумга төшәчәк. «Алар машина номерларын «укып», «тимер ат» хуҗасына түләү кәгазен автомат рәвештә җибәрәчәк. «Әгәр машинагыз реестрга кертелгән һәм бу җирлектә яшәүче буларак юлның шушы өлешендә бушлай йөрү рөхсәт ителгән икән, сезгә андый «сәлам хаты» бөтенләй килмәячәк», – ди министр.

Яңа трасса төзегәндә сафтан чыккан «иске юл»ларны да онытмаска вәгъдә бирәләр. Аларның күбесе мондый зур йөкне чыдатырлык дәрәҗәдә түгел. Шуңа күрә бик тиз сафтан чыгалар. Фәрит Хәнифов сүзләренә караганда, яңа трасса төзелешенә тәүлек әйләнәсе материал ташучы йөк машиналары йөргән юллар да соңыннан төзекләндереләчәк. Бу төбәк һәм җирле юллардан тыш, Чаллы һәм Түбән Кама аша узучы М7 трассасына да кагыла.

– Бүген яңа төзелүче М12 трассасына илтүче 250 чакрым юл исәпләнә. Шундый зур төзелеш барганда һәр подрядчы оешма аларны төзекләндереп, тәртипләп тора. Төзүчеләр үзләре дә, җирле халык та бу юллардан хәвеф-хәтәрсез генә йөрсен өчен эшләнә бу. Бераз сабыр итәргә туры киләчәк. Төп юл кулланылышка тапшырылгач, аны төзегәндә файдаланылган юллар капиталь төзекләндереләчәк, алар элеккедән дә сыйфатлырак булачак, – дип ышандыра министр. – Түләүле юллар үзебезнең гади юллар белән кисешергә тиеш түгел, билгеле. Шуңа күрә һәр 50 чакрымнан соң развязкалар куела.

Сүз уңаеннан, М12 трассасы буйлап сәгатенә уртача 120–140 чакрым тизлек белән хәрәкәт итәргә рөхсәт ителәчәк. Әмма, Марат Хөснуллин сүзләренә караганда, аның кайбер өлешләрендә тизлекне сәгатенә 150 чакрымга кадәр арттырырга мөмкин булачак.

Президент юбилей белән котлады

Түбән Кама «Нефтехим» гавами акционерлык җәмгыятенә нигез салынуга 55 ел тулды. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов анда эшләүчеләргә предприятиенең генераль директоры Игорь Климов исеменә котлау юллады.

– Татарстанда нефть-химия сәнәгате Түбән Кама нефть-химия комбинатыннан башланды, – диелә котлауда. – 1967 елда предприятие эшләп чыгарган тәүге продукция производствоны үстерү һәм ныгытуга өзлексез юл салды. Тырыш хезмәт нәтиҗәсендә ил каучук һәм пластикның яңа төрләренә ия булды. Химкомбинат уңышлары илебезнең нефть химиясен үстерү тарихында алтын хәрефләр белән уелып калды.

Предприятиенең тормышы нефтехимикларның тулы бер династияләре язмышына бәйле. Биредә күпләр үзләренең парларын тапты, гаиләләр корды, балалар үстерде. Буыннарның дәвамчанлыгы заводта дистәләрчә еллар дәвамында булдырылган данлыклы традицияләрне саклый. Түбән Кама «Нефтехим» җәмгыятенең бөтен коллективын, кадерле ветераннарны предприятиенең 55 еллыгы уңаеннан эчкерсез котлыйм! Һәркайсыгызга нык сәламәтлек, бәхет һәм хезмәттә яңа үрләр телим!

Яшенләп, давыллап башлана

Җылы көннәре, вакытында яуган яңгырлары белән истә калачак. Синоптиклар август аенда һава торышы шундый булыр дип фаразлый. Күреп торабыз: аларның июль аена фаразлары чынга ашты. Эссе көннәре, чиллә белән башланган июль аеның икенче яртысы явым-төшемнәргә бай булды.

КФУның Экология һәм табигатьтән файдалану институтының метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев август аенда уртача һава температурасы 18 градус чамасы булачак, 54 мм явым-төшем явачак, дип ышандыра.

– Июль аенда чын җәйгә хас эсселек күзәтелде, яңгырлар мул булды. Бу айда 79 мм явым-төшем теркәлде. Нормада ул 63 миллиметрдан артмаска тиеш иде. Шул рәвешле җәйнең икенче ае июнь «план»ын да тутырды. Гомумән, алты ел рәттән июль аенда явым-төшемнәр климатик нормадан артып китә. Бу ай нәтиҗәләре буенча Татарстанда уртача һава температурасы 21,5 градус тәшкил итәчәк. Климатик нормадан бер градуска югарырак бу, – ди Тимур Әүхәдиев.

Синоптиклар алдагы ике тәүлектә дә яңгырлы һава торышы вәгъдә итә. Татарстан Гидрометеорология үзәге мәгълүматларына караганда, бүген һәм иртәгә республикада кыска вакытлы яшенле яңгырлар, көчле җил көтелә. Көндез һава температурасы 28 градуска кадәр җылыначак.

Балтач районы Арбор авылында яшәүче «халык синоптигы» Әмир Шәрәфиев, быел августтагы җылылар сентябрьдә дә дәвам итәчәк, дип ышандыра. Моны быелгы һава торышының алдагы елдагылары белән чагыштырганда үзгәрәк булуы белән аңлата ул. «Быел кышның соңгы ае җылы булды. Февраль урынына март килгән кебек иде. Мартта исә, киресенчә, салкыннар сакланды. Апрель ике айга сузылды. Май өч көн генә булып калды. Аның бер өлеше июньгә күчте – көннәр салкын торды. Шуңа күрә быел чын җәй август белән сентябрьгә авыша. Урып-җыю башланган көннәрдә, елдагыча, бозлар явып, давыллап, һава торышы бозылып алыр әле», – дип фаразлый «халык синоптигы».

Һава торышы дигәнең ел азагына таба да көтелмәгән «сюрприз»лар белән шаккатырырга охшап тора. Синоптиклар сүзләре белән әйтсәк, «тизрәк онытасы килгән куркыныч төш»не хәтерләтәчәк ул. Белгечләр, октябрь аенда һава торышы әнә шулай холыксызланачак, дип фаразлый. «Октябрь аенда Идел буе төбәгендә явым-төшемле салкын һава торышы көтелә. Ай башында һәр көнне көчле яңгырлар явачак. Татарстанда терекөмеш баганасы 10 градустан өскәрәк күтәрелмәячәк. Мәскәү һәм Мәскәү янында да шундый ук һава торышы сакланачак. Бер-ике атнадан исә җылылык 5 градустан да артмаячак», – дип фаразлый синоптиклар. Әлегә исә җәйнең кадерен белеп калыйк.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Август аена халык сынамышлары

✓ Августның беренче атнасында тотрыклы һава торышы сакланса, кыш озын һәм карлы булыр.
✓ Август яңгырсыз килсә – җылы һәм коры көзгә.
✓ Августта бәс төшсә, иртә кышка ишарә.
✓ Августта берничә тапкыр яшен булса, көз озак булыр.
✓ Җылы, яңгырлы август – гөмбә уңышына.
✓ Августта торналар төркем-төркем булып җылы якка китсә, кыш иртә килер.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 14 июлендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны каплау турында дәгъвалар бирү;»;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа утыз тугызынчы абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы белән килештереп, әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм бәяләү, һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү эшләрен оештыру, һәм (яисә) хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмый калуның һәм (яисә) киметүнең, табигый мохитне саклауның һәм торгызуның, табигать ресурсларыннан рациональ файдалануның һәм аларны торгызуның, экологик иминлек тәэмин итүнең башка чараларын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасының чаралар планын раслау;»;

в) утыз тугызынчы абзацны кырыгынчы абзац дип санарга;

2) 46 статьяда:

а) 1 өлешнең 2 пунктында «һәм аның компонентларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «һәм аның компонентларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 91 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Су объектларыннан файдаланганда, физик затлар, юридик затлар дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге су объектларын өйрәнү, алардан файдалану, аларны саклау, шулай ук суларның тискәре йогынтысын булдырмый калу һәм аннан килгән зыяннарны бетерү гамәлләрен (алга таба – суга кагылышлы хуҗалык гамәлләре) федераль законнар нигезендә башкарырга тиеш.»;

4) 98 статьяның 13 өлешендәге 1 пунктында «туфракның уңдырышлылыгын көйләү» сүзләрен «туфрак уңдырышлылыгын арттыру» сүзләренә алмаштырырга;

5) 100 статьяда:

а) 1^1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1^1. Суларның аерым территорияләргә һәм объектларга тискәре йогынтысын булдырмый калу һәм аннан килгән зыяннарны бетерү максатларында суларның тискәре йогынтысын булдырмый калу һәм аннан килгән зыяннарны бетерү буенча Россия Федерациясе Су кодексының 67^1 статьясында каралган чаралар гамәлгә ашырыла.» ;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1^1 өлешендә күрсәтелгән чаралар Россия Федерациясе Су кодексының 7^1 статьясында каралган суга кагылышлы хуҗалык гамәлләре кысаларында гамәлгә ашырыла.».

2 статья

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының беренче, дүртенче – алтынчы абзацлары 2022 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының икенче һәм өченче абзацлары һәм 2 пункты 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 25 июль
№ 44-ТРЗ

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32^1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 14 июлендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 32 статьяның 3 пунктында:

а) 1 пунктчада «индивидуаль торак» сүзләре алдыннан «әгәр мондый гражданнар җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәсәләр һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә торсалар,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнар, әгәр җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында ата-ананың берсе генә булса да яисә ялгыз ата йә ана Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәсә, әлеге пунктның 1 пунктчасында каралган җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү таләбенә туры килә дип санала.»;

2) 32^1 статьяда:

а) 10 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 8 һәм 9 пунктчалар өстәргә:

«8) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗ буларак исәптә торуын раслаучы документ;

9) мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турындагы суд карары (мөрәҗәгать итүченең паспортында җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында аны Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәү билгесе булмаган очракта).»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның 8 пунктчасында күрсәтелгән документ, мөрәҗәгать итүче аны үзе тапшырмаган булса, вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.»;

б) 12 пунктта:

«мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган» сүзләреннән соң «яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан алынган» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гражданнарга аларны исемлекләргә кертүдән баш тарту турында хәбәр вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән алып җиде көннән дә соңга калмыйча тапшырылуы хакында хәбәр ителә торган заказлы хат белән җибәрелә йә аларга имза куйдырып тапшырыла.»;

в) 13 пунктта:

беренче абзацта «, әлеге статьяның 15 пунктында каралган очраклардан тыш, аларны исемлекләргә керткән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «җир кишәрлекләрен сайлап алу процедурасын» сүзләрен «җир кишәрлеген сайлап алу процедурасын» сүзләренә алмаштырырга;

г) 15 пунктта:

2 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«д) социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә торудан төшереп калдыру.»;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) гражданнар җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында җир кишәрлеген сайлап алудан өч мәртәбә баш тартса, йә гражданнар җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә килми калса, йә гражданнарның җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында җир кишәрлеген сайлап алудан баш тарту һәм аларның җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына килми калу очраклары барысы бергә өчкә тигез булса;»;

д) 17 пунктта:

беренче абзацта «әлеге статьяның 10 пунктында» сүзләрен «әлеге статьяның 10 пунктындагы 1 – 7 пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән документлар, мөрәҗәгать итүче аларны үзе тапшырмаган булса, вәкаләтле җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль соратып алына.».

2 статья

1. Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр җир кишәрлеге бирү турында гариза тапшырган, әмма аларны Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлеге алу хокукы булган гражданнар исемлекләренә (алга таба – исемлекләр) кертү турында карар кабул ителмәгән өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга карата мондый карарны кабул итү, гражданнарның Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен Татарстан Республикасы Җир кодексының 32^1 статьясындагы 15 пунктында каралган бәяләүне гамәлгә ашыру һәм җир кишәрлеген бирү гражданнарның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү срогын һәм аларның социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә тору-тормавын исәпкә алмыйча башкарыла.

2. Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр исемлекләргә кертелгән өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга карата гражданнарның Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен Татарстан Республикасы Җир кодексының 32^1 статьясындагы 15 пунктында каралган бәяләүне гамәлгә ашыру һәм җир кишәрлеген бирү гражданнарның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү срогын һәм аларның социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә тору-тормавын исәпкә алмыйча башкарыла.

3. Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр җир кишәрлеге бирү турында гариза тапшырган, әмма аларны исемлекләргә кертү турында карар кабул ителмәгән өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга, шулай ук әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр исемлекләргә кертелгән өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга карата Татарстан Республикасы Җир кодексының 32^1 статьясындагы 13 пунктының беренче абзацы әлеге Закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алмыйча кулланыла.

4. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32^1 статьясындагы 15 пунктының 4 пунктчасы нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр исемлекләргә кертелгән өч һәм аннан күбрәк балалы гражданнарга карата кулланылмый. Күрсәтелгән гражданнар исемлекләрдән төшереп калдырыла һәм аларга, гражданнар җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында җир кишәрлеген сайлап алудан өч мәртәбә баш тартса йә гражданнар җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә килми калса, җир кишәрлеге бирүдән баш тартыла.

3 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 30 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 25 июль
№ 45-ТРЗ

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 14 июлендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«7) «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын арттыру программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру» федераль проекты кысаларында сатып алынган автомобиль транспорты булган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан түбәндәгеләрне китерү:

авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны медицина оешмаларына;

авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны һәм инвалидларны социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына.».

2 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешенең 7 пункты 2024 елның 31 декабренә кадәр (шул көнне кертеп) гамәлдә була.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 25 июль
№ 46-ТРЗ

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 14 июлендә кабул ителде

1 статья

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Инвалидларны эшкә алу өчен квота Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эш бирүчеләр өчен түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1) хезмәткәрләренең саны 35 кешедән алып 100 кешегә кадәр булган, 100 кешене кертеп, эш бирүчеләргә – хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача санынннан 2 процент күләмендә;

2) хезмәткәрләренең саны 100 кешедән артык булган эш бирүчеләргә – хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан 3 процент күләмендә билгеләнә.»;

б) 7 – 9 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

в) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарының минималь саны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмәгә таянып, инвалидларны эшкә алу өчен квота чикләрендә билгеләнә.»;

2) 5 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эш бирүчеләр тарафыннан эш урыннары резервлана, аларның саны Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.»;

3) 6 статьяның 2 өлешендә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәргә, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен иң туры килә торган һөнәрләр буенча, шулай ук социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын резервларга;»;

б) 2^1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтле органы» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» һәм «б» пунктчалары 2022 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 25 июль
№ 47-ТРЗ

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 14 июлендә кабул ителде

1 статья

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында»;

2) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны (алга таба – даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу) оештыруның аерым мәсьәләләрен җайга сала, шулай ук даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгели.»;

3) 3 статьяда:

а) 1 өлештә түбәндәге эчтәлекле 3^2 пункт өстәргә:

«3^2) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын (алга таба – вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы) билгели;»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы:

1) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларын эшли;

2) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын эшли һәм аны гамәлгә ашыра;

3) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның дәүләт заказчысы функцияләрен башкара, дәүләт контрактын төзи һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирә;

4) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурсны оештыручы функцияләрен башкара, мондый конкурста катнашуга заявкаларның критерийларын бәяләү өчен шкала билгели, йөртүчеләргә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирә;

5) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурсны үткәрү турында хәбәрне һәм аңа кертелгән үзгәрешләрне үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибен билгели;

6) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашуга заявка рәвешен һәм әлеге заявканың эчтәлегенә (шул исәптән ачык конкурста катнашучының тәкъдимен тасвирлауга) таләпләрне билгели;

7) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара һәм муниципальара маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тукталыш пунктларының исемлеген төзи;

8) Татарстан Республикасы чикләрендә уза торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларына таләпләрне билгели;

9) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен, аңа даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча гамәлгә ашырыла торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төрен үзгәртү турында белешмәләр кертү тәртибен раслый, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бара;

10) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибен (шул исәптән юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның шушы маршрутларны билгеләү, үзгәртү йә туктату турындагы гаризаларын карау тәртибен, шулай ук шушы маршрутларны билгеләүдән йә үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләрне, шушы маршрутларны туктату өчен нигезләрне) раслый, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгели, үзгәртә һәм туктата;

11) автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләүне гамәлгә ашыра;

12) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә үз компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

4) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнары даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә:

1) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итәләр;

2) үз компетенциясе чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслыйлар, бу документны кабул итәләр һәм гамәлгә ашыралар;

3) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль заказчысы функцияләрен башкаралар, муниципаль контракт төзиләр һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирәләр;

4) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурсны оештыручы функцияләрен башкаралар, мондый конкурста катнашуга заявкаларның критерийларын бәяләү өчен шкала билгелиләр, йөртүчеләргә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирәләр;

5) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурсны үткәрү турында хәбәрне һәм аңа кертелгән үзгәрешләрне даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын билгеләгән вәкаләтле җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибен билгелиләр;

6) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашуга заявка рәвешен һәм әлеге заявканың эчтәлегенә (шул исәптән ачык конкурста катнашучының тәкъдимен тасвирлауга) таләпләрне билгелиләр;

7) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып бару тәртибен, аңа даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча гамәлгә ашырыла торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төрен үзгәртү турында белешмәләр кертү тәртибен раслыйлар, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып баралар;

8) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибен (шул исәптән юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның шушы маршрутларны билгеләү, үзгәртү йә туктату турындагы гаризаларын карау тәртибен, шулай ук шушы маршрутларны билгеләүдән йә үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләрне, шушы маршрутларны туктату өчен нигезләрне) раслыйлар, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның му-

ниципаль маршрутларын билгеләүләр, үзгәртүләр һәм тукталалар;

9) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан тукталыш пунктларының исемлеген төзиләр;

10) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан тукталыш пунктларын билгеләү буенча тәкъдимнәр җибәрәләр;

11) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында җәйгә салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга, кирәк булган очракта, таләпләр билгеләргә;

12) автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль кысаларында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләүне гамәлгә ашыралар;

13) даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә үз компетенцияләренә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.»;

5) түбәндәге эчтәлекле 4^1 статья өстәргә:

«4^1 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары арасында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру буенча вәкаләтләрне бүлешү**

Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының әлеге Законда каралган вәкаләтләре алар арасында «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1^2 өлешендә каралган тәртиптә бүленергә мөмкин.»;

6) 5 статьяда:

а) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршрутлары реестрларына шушы маршрутлар турында Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешенең 1 – 11 пунктларында каралган белешмәләр кертелгән көннән, әлеге реестрларда шушы маршрутлар турында Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешенең 3 – 11 пунктларында каралган белешмәләр үзгәртелгән көннән тиешенчә билгеләнгән яисә үзгәртелгән дип санала һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршрутлары реестрларыннан шушы маршрутлар турында белешмәләр төшереп калдырылган көннән туктатылган дип санала.»;

б) 8 – 10 өлешләрне үз көчен югалткан дип танырга;

7) түбәндәге эчтәлекле 5^1 статья өстәргә:

«5^1 Статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрлары**

1. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару шушы маршрутларны билгеләгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын алып бару шушы маршрутларны билгеләгән вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларына Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешендә каралган белешмәләр кертелергә тиеш. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларына кертелгән белешмәләр (индивидуаль эшкуарның торү урыны турындагы белешмәләрдән тыш) үз вәкаләтләрендә шушы реестрларны алып бару кертелгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең органының яисә вәкаләтле җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

8) 6 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җәйгә салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы йә башка дәүләт заказчысы яисә муниципаль заказчы тарафыннан, Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт контрактлары яисә муниципаль контракт төзү юлы белән;

2) концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнары, дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында Россия Федерациясе законнары нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен шәһәр җир өсте электр транспортындагы транспорт чараларыннан (трамвайлардан, троллейбуслардан), тышкы чыганактан корыла торган батареядагы электр энергиясе белән хәрәкәткә китерелә торган автобуслардан (электробуслардан) файдалануны һәм аларның хәрәкәтен технологик яктан тәэмин итү торган объектларны эксплуатацияләүне күздә тоткан концессия килешүе, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү төзү юлы белән, – әгәр бу даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документында яисә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең региональ комплекслы планында каралган булса.»;

б) 4 өлештә «Федераль законда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган ачык конкурс нәтиҗәләре буенча бирелгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 7 статьяда:

а) 2 өлештә «ачык конкурс» сүзләрен «даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча эшчәнлек алып бару хокукына ачык конкурс» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 өлешнең 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

10) түбәндәге эчтәлекле 7^2 статья өстәргә:

«7^2 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара һәм халыкара маршруты буенча автовокзаллар яисә автостанцияләр территорияләреннән читтә урнашкан тукталыш пунктларыннан файдалану**

1. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара яисә халыкара маршруты буенча тукталыш пунктлары автовокзаллар яисә автостанцияләр территорияләрендә урнашырга тиеш. Татарстан Республикасы территориясендә башка тукталыш пунктларыннан файдалану вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының норматив хокукый актында каралган очракта рөхсәт ителә.

2. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара яисә халыкара маршруты буенча автовокзал йә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары, әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракта, Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләр нигезендә җиһазландырылган булырга тиеш. Автовокзал йә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары күрсәткечләрендә регионара яисә халыкара маршрут буенча мәгълүмат урнаштыру вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан оештырыла.»;

11) түбәндәге эчтәлекле 7^3 статья өстәргә:

«7^3 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны тоткарлыксыз гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру**

1. Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны тоткарлыксыз гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән муниципаль берәмлекләр территорияләрендә заказ буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланыла торган бер үк транспорт чарасын бер ай эчендә өч тапкырдан артык җибәрү тыелган урыннар яисә алардан җибәрү вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белән килештерелергә тиеш булган урыннар билгеләнергә мөмкин.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган транспорт чарасын җибәрүне килештерү (шул исәптән мондый килештерүдән баш тарту өчен нигезләр) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

2 статья

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 10 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 10 пункты 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 25 июль
№ 48-ТРЗ

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 14 июлендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенең 9 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«9) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итү актын имзалау тәртибен һәм срокларын, шулай ук мондый актны имзалауда катнашучыларның, шул исәптән күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яисә) башкарылган эшләрне кабул итүне гамәлгә ашыручы комиссия белән дә, үзара эшчәнлеге тәртибен билгеләү;».

2 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 25 июль
№ 49-ТРЗ

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 14 июлендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 27 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 3 (I өлеш), «2023 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 25 июль
№ 50-ТРЗ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратының Капиталь төзелеш идарәсе проектлар җитәкчесе **Городний** Виктор Исакович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының сәнәгать потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Кәримуллин** Дамир Җәүдәт улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасында спортның техник төрләрен үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Ак Барс Галерея» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Ак Барс Ретро» структур бүлекчәсе механигы **Гатиятов** Ринат Гомәр улы; республиканың урман хуҗалыгын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Саба урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесенең җитәкче-урманчысы **Гыйззәтуллин** Васыйл Нурулла улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, актив иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге өчен шәхси эшкуар **Динмөхәммәтов** Шамил Шәфик улы; республиканың юл-транспорт төзелешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «1 нче районара юл төзелеше идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Ильясов** Рашит Мәгъсүм улы; сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Медицина техникасы» Кама арьягы сәүдә-сервис берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Муллин** Геннадий Николаевич; законлылыкны ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Суды суд составы рәисе **Шашмаркин** Виктор Владимирович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Атнаголов** Ирек Хикмәтелгаян улы; мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүләре, күпьеллык намуслы хезмәтләре һәм актив иҗтимагый эшчәнлекләре өчен «Я.Е. Емельянов исемендәге мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, Татарстан Республикасы керәшеннәренең иҗтимагый оешмасы идарәсе әгъзасы **Белоусова** Людмила Даниловна; «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының авылара мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы халыклары бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре һәм йолалары буенча методисты, «БЕРДӘМ РОССИЯ» Бөтенроссия сәяси партиясе Төбәк башкарма комитетының Партиянең җирле бүлекчәләре эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге Татарстан төбәк бүлекчәсенең Чүпрәле җирле бүлекчәсе башкарма секретаре **Каюмов** Илдар Ирфан улы; республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Ганиев** Илдар Марсель улы; республикада һөнәр берлекләре хәрәкәтен үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык намуслы хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре һөнәр берлегенең Татарстан Республикасындагы төбәк оешмасы баш белгече **Гафарова** Гөлсинә Әсхәт кызы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Бөтендөнья татар конгрессының республика иҗтимагый фонды баш референты **Гыйльметдинова** Лилия Хәйретдин кызы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родина» колхозы баш агрономы **Кадыйров** Илмирад Габделхәй улы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү һәм укучыларга йомгаклау аттестациясе уздыру бүлеге башлыгы урынбасары **Лустина** Татьяна Михайловна; эчке эшләр органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен полиция полковнигы **Мостафин** Наил Фоат улы; җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Нәфис Косметикс» акционерлык җәмгыяте – М. Вахитов исемендәге Казан химия комбинатының (Крестовниковларның элеккеге 1 номерлы сабын һәм шәм заводы) 18 номерлы цехы башлыгы **Хуҗәхмәтов** Рәүфәт Өлфәт улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе Биектау районара тикшерү бүлеге җитәкчесе, юстиция подполковнигы **Мөгыйнов** Рөстәм Абрик улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры урынбасары **Әбүзәров** Айрат Рафаэль улына; «ТСИ» торак төзүче махсуслаштырылган оешмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җитештерү-техник бүлеге техник күзәтчелек буенча әйдәүче инженеры **Арзамасцев** Николай Александровичка; «Модульстрой» төзелеш-җитештерү компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры урынбасары **Ильясов** Исрафил Фәрваз улына; «СтройСити» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең капиталь төзелеш бүлеге баш инженеры **Ситдыйков** Харис Нури улына; «Автодор» төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Шәйдуллин** Рамил Фоат улына; «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлеге баш белгече **Сергеев** Алексей Яковлевичка **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Төбәкара хезмәттәшлекне ныгытудагы казанышлары һәм Лениногорск муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы **Хөсәенов** Рәгать Галиәгъзам улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Дүсмәт урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе китапханәчесе, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Балалар һәм яшүсмерләр йорты» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесенең берьюлы ике урында эшләп өстәмә белем бирү педагогы вазыйфаларын башкаручы **Әхмәдиева** Зоя Васильевнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Кондитерлык ательесы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кондитерлык эшләнмәләре пешерүчесе **Прохорова** Марина Васильевнага **«Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Чирмешән муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы **Әхмәдуллина** Рушания Солтан кызына; Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Сарман муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы **Гыйльметдинова** Лилия Мирзаһит кызына; «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Саба муниципаль районындагы «Балкыш» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәсе мөдире **Фатыйхова** Суфия Хәбибулла кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Сарсаз-Баграж төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура укытучысы **Утяганов** Петр Петровичка **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Диплом медсестры общего профиля, выданный Казанским медицинским училищем в 1993 или 1994 году на имя Шириевой Гульнары Рафисовны, 01.02.1974 г.р., в связи с утерей считать недействительным.

Белдерү

Кадастровым инженером Кутдусовой Натальей Генадьевной (СНИЛС № 128-830-216 57), являющейся членом СРО АКИ "Поволжье" (номер в реестре СРО "0182", дата вступления 05.07.2013 г.), квалификационный аттестат № 16-11-417, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1, адрес электронной почты: m2405085@yandex.ru, тел.: 8(843)2405085, в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:16:120305:53, расположенного по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, с. Чебакса, ул. Советская, д. 5, выполняются кадастровые работы по уточнению границ и площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Наумова Н.В. (тел.: 8-9053138514). Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования границ состоится по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1 2 сентября 2022 г. в 10.30 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1. Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются ежедневно с 9 до 17 часов 1 августа 2022 до 2 сентября 2022 г. по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1.

Смежный земельный участок с правообладателем, которого требуется согласовать местоположение границ 16:16:120305:52, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, с. Чебакса, ул. Советская.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

Кадастровым инженером Кутдусовой Натальей Генадьевной (СНИЛС № 128-830-216 57), являющейся членом СРО АКИ «Поволжье» (номер в реестре СРО 0182, дата вступления 05.07.2013 г.), квалификационный аттестат № 16-11-417, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1, адрес электронной почты: m2405085@yandex.ru, тел.: 8(843)2405085, в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:24:254501:158, расположенного по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Орловское сельское поселение, тер. тсн N4 «Чистое озеро» завода Радиоприбор, з/у 18 А, выполняются кадастровые работы по уточнению границ и площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Гайнуллина М.М. (тел.: 8-9586266171). Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования границ состоится по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1 2 сентября 2022 г. в 10.30 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1. Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с ежедневно с 9 до 17 часов с 1 августа 2022 до 2 сентября 2022 по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1.

Смежный земельный участок с правообладателем, которого требуется согласовать местоположение границ 16:24:254501:234, расположенный по адресу: Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Орловское сельское поселение, некоммерческое садоводческое товарищество № 4 «Чистое озеро» завода "Радиоприбор", участок 16 А.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

Кадастровым инженером Сидоровым Александром Владимировичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-11-196, СНИЛС 085-734-145 87, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность № 6391, 423700, Республика Татарстан, г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19, контактный телефон: 8(85555)3-19-60), подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельной доли Мирзаяновой Хазяре Асылгараевне из земельного участка с кадастровым номером 16:04:000000:261, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Актанышский муниципальный район, на землях СПК «Сафар». Заказчиком работ является Мирзаянова Хазяра Асылгараевна (РТ, Актанышский муниципальный район, с. Ст. Сафарово, ул. Г.Сафиуллина, д. 7, тел.: 89179244493).

С проектом межевания можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч., кроме субботы и воскресенья, по адресу: г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.

Кадастровый инженер Сидоров А.В.

Кадастровым инженером Сидоровым Александром Владимировичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-11-196, СНИЛС 085-734-145 87, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность № 6391, 423700, Республика Татарстан, г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19, контактный телефон: 8(85555)3-19-60), подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельной доли Мирзаяновой Раушание Фирдависовне из земельного участка с кадастровым номером 16:04:000000:261, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Актанышский муниципальный район, на землях СПК «Сафар». Заказчиком работ является Мирзаянова Раушания Фирдависовна (РТ, Актанышский муниципальный район, с. Ст. Сафарово, ул. 8 Марта, д. 14, тел.: 89179244493).

С проектом межевания можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч., кроме субботы и воскресенья, по адресу: г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.

Кадастровый инженер Сидоров А.В.

Кадастровым инженером Сидоровым Александром Владимировичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-11-196, СНИЛС 085-734-145 87, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность № 6391, 423700, Республика Татарстан, г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19, контактный телефон: 8(85555)3-19-60), подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельной доли Мирзаянову Тагиру Амирзяновичу из земельного участка с кадастровым номером 16:04:000000:261, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Актанышский муниципальный район, на землях СПК «Сафар». Заказчиком работ является Мирзаянов Тагир Амирзянович (РТ, Актанышский муниципальный район, с. Ст. Сафарово, ул. 8 Марта, д. 14, тел.: 89179244493).

С проектом межевания можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч., кроме субботы и воскресенья, по адресу: г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.

Кадастровый инженер Сидоров А.В.

Кадастровым инженером Сидоровым Александром Владимировичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-11-196, СНИЛС 085-734-145 87, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность № 6391, 423700, Республика Татарстан, г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19, контактный телефон: 8(85555)3-19-60), подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельной доли Шайгардановой Илюзе Дульфатовне из земельного участка с кадастровым номером 16:04:000000:261, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Актанышский муниципальный район, на землях СПК «Сафар». Заказчиком работ является Шайгарданова Илюза Дульфатовна (РТ, Актанышский муниципальный район, с. Ст. Сафарово, ул. Х. Такташ, д. 16, тел.: 89179244493).

С проектом межевания можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч., кроме субботы и воскресенья, по адресу: г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.

Кадастровый инженер Сидоров А.В.

Кадастровым инженером Сидоровым Александром Владимировичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-11-196, СНИЛС 085-734-145 87, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность № 6391, 423700, Республика Татарстан, г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19, контактный телефон: 8(85555)3-19-60), подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельной доли Шайгарданову Ленару Шариповичу из земельного участка с кадастровым номером 16:04:000000:261, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Актанышский муниципальный район, на землях СПК «Сафар». Заказчиком работ является Шайгарданов Ленар Шарипович (РТ, Актанышский муниципальный район, с. Ст. Сафарово, ул. Х. Такташ, д. 16, тел.: 89179244493).

С проектом межевания можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч., кроме субботы и воскресенья, по адресу: г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.

Кадастровый инженер Сидоров А.В.

Кадастровым инженером Сидоровым Александром Владимировичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-11-196, СНИЛС 085-734-145 87, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность № 6391, 423700, Республика Татарстан, г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19, контактный телефон: 8(85555)3-19-60), подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельной доли Яруллиной Гульнаре Гилемяновне из земельного участка с кадастровым номером 16:04:000000:261, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Актанышский муниципальный район, на землях СПК «Сафар». Заказчиком работ является Яруллина Гульнара Гилемяновна (РТ, гор. Наб. Челны, ул. Раскольникова, д. 49Б, кв. 146, тел.: 89179244493).

С проектом межевания можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч., кроме субботы и воскресенья, по адресу: г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.

Кадастровый инженер Сидоров А.В.

Кадастровым инженером Сидоровым Александром Владимировичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-11-196, СНИЛС 085-734-145 87, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность № 6391, 423700, Республика Татарстан, г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19, контактный телефон: 8(85555)3-19-60), подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельной доли Мухамутдинову Насиху Асхатовичу из земельного участка с кадастровым номером 16:04:000000:261, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Актанышский муниципальный район, на землях СПК «Сафар». Заказчиком работ является Мухамутдинов Насих Асхатович (РТ, Актанышский муниципальный район, с. Ст. Сафарово, ул. Х. Такташ, д. 1, тел.: 89179244493).

С проектом межевания можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч., кроме субботы и воскресенья, по адресу: г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.

Кадастровый инженер Сидоров А.В.

Кадастровым инженером Сидоровым Александром Владимировичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-11-196, СНИЛС 085-734-145 87, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность № 6391, 423700, Республика Татарстан, г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19, контактный телефон: 8(85555)3-19-60), подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельной доли Мухамутдиновой Кадерие Мухтаровне из земельного участка с кадастровым номером 16:04:000000:261, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Актанышский муниципальный район, на землях СПК «Сафар». Заказчиком работ является Мухамутдинова Кадерия Мухтаровна (РТ, Актанышский муниципальный район, с. Ст. Сафарово, ул. Х. Такташ, д. 1, тел.: 89179244493).

С проектом межевания можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч., кроме субботы и воскресенья, по адресу: г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.

Кадастровый инженер Сидоров А.В.

Кадастровым инженером Сидоровым Александром Владимировичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-11-196, СНИЛС 085-734-145 87, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность № 6391, 423700, Республика Татарстан, г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19, контактный телефон: 8(85555)3-19-60), подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельной доли Масалимовой Разине Асхатовне из земельного участка с кадастровым номером 16:04:000000:261, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Актанышский муниципальный район, на землях СПК «Сафар». Заказчиком работ является Масалимова Разина Асхатовна (РТ, Актанышский муниципальный район, с. Ст. Сафарово, тел.: 89179244493).

С проектом межевания можно ознакомиться ежедневно с 8.00 до 17.00 ч., кроме субботы и воскресенья, по адресу: г. Мензелинск, ул. Тукая, д.19.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.

Кадастровый инженер Сидоров А.В.

РӨСТӘМ УСМАНОВ:
«ИРТӘН ТОРУГА, ЧӘЙНЕК СЫЗГЫРСА, ДИМӘК, БЕЗ ЭШЛИБЕЗ»

Яшәеш

Татарстанда газлаштыру программасы дәвам итә. «Газпром трансгаз Казан» оешмасы быелгы алты айда республика халкын 8,1 млрд кубометр ягулык белән тәэмин иткән. Газлаштыру эшләре ничек бара? Газчылар экология хакында кайгыртамы? Оешма хезмәткәрләре нинди шартларда яши? Шул хакта «Газпром трансгаз Казан» оешмасының генераль директоры Рөстәм УСМАНОВ белән сөйләштек.

«Татар-информ»

:: Рөстәм Ринатович, илдә барган вазгыять оешмаларны яңа икътисади шартларда эшләргә өйрәнергә мәҗбүр итте. Бу сезнең эшчәнлеккә дә йогынты ясадымы?

– "Газпром трансгаз Казан" оешмасына илдәге вазгыять берничек тә комачау итмәде. Бар да элеккечә калды. Быел алты айда республика халкын 8 млрд кубометр газ белән тәэмин иттек. Ел ахырына кадәр бу сан 18 млрд кубометрга җитәр, дип өметләнәбез. Татарстан, газ куллану буенча Мәскәүдән генә калышып, икенче урында бара. Тик торырга вакыт юк. Газ юлларын, челтәрләрен төзекләндерү эшләре дәвам итә. Ярты елга куелган планны арттырып үтәдек. Әлеге вакытта кышка әзерләнәбез. Газчыларның шул инде ул: башта кыш чыгуны кайгыртабыз, аннан язгы ташу өчен борчылабыз, аннан тагын җәй-көз айларында тәэкелләндерү эшләренә тотынабыз. Максат бер – иң элек Татарстан халкын зәңгәр ягулык белән тәэмин итү. Республикада безнең 1 миллион 600 мең кулланучыбыз бар. Алар кыенлыклар белән очрашырга тиеш түгел. Газны читкә татарга да кайгыртабыз. Россия төбәкләре, күп кенә илләр безнең зәңгәр ягулыкны көтеп тора.

:: Республикада газлаштыру программасы ничек бара? Шул хакта да сөйләп китсәгез иде.

– Догазификация программасы нигезендә 18 мең йортка газ кертелер дип көтелә. Гаризалар күп булса, бу сан үзгәрергә дә мөмкин. Исегезгә төшерәбез: газлаштыру программасы буенча газчылар теләгән кешенең капка төбенә кадәр зәңгәр ягулык китерә. Анысы бушка була. Өенә кадәр газ үткәрер өчен акча түлисе. Быел без 4 мең кешенең йорт янына кадәр, 880 өйгә газ керттек. Кышка таба газ кертүне сораучылар артыр дип торабыз. Республикада кайбер төр категория гражданнарга (Бөек Ватан сугышы ветераннарына, өч яки аннан күбрәк баласы булган гаиләләргә, I һәм II группа инвалидларга, инвалид баласы булган яки керемнәре кеше башына 10 меңнән 19 мең сумга кадәр булган гаиләләргә) газны өенә керткән өчен дәүләт 80 мең сум күләмендә субсидия да бирә.

Үзегез күреп торасыз, республика үсештә, сәнәгать оешмалары төзелә. Шунлыктан, Алабуга, Түбән Кама шәһәрләрендә газ куллану артканнан-арта. 2030 елга без республика өчен газ җитештерү күләмен 33 млрд кубометрга җиткерергә уйлыйбыз. Күптән түгел "Газпром" белән Татарстан җитәкчелеге килешү төзеде. Тиздән авыллар арасында газ кертү программасы эшли башлаячак. Ул 3 елга исәпләнгән. Бу эш "Газпром" акчасына башкарыла. Газ кертү өчен 2,03 миллиард сум акча бүлеп бирелде. Без һәрвакыт газга ихтыяҗны канәгатьләндерергә әзер булырга тиеш.

:: Сер түгел, эре сәнәгать оешмалары экологиягә дә зыян сала. Сездә хәлләр ничек? Бу вазгыятьне ничек хәл итәсез?

– Безнең өчен экология мәсьәләсе – беренче урында. Башкача мөмкин дә түгел! Без табигатькә зыян салмаска тырышабыз. Салабыз икән, аны шундук яхшырту ягын карыйбыз. Үзебез яшисе җир бит. Моны оешмада эшләүчеләр дә яхшы аңлый. Чүпне хәзер аерып җыеп, утильләштерәбез. Заманча чүп савытлары куябыз, экологик акцияләрдә катнашабыз. Яшьләр өмәләрне калдырмый. Безнең газүткәргечләребез сулыклар аша да уза. Шуны истә тотып, без килгән зыянны капларга тырышабыз. Шунлыктан елгаларга кыйммәтле балыклар алып җибәрәбез.

:: Оешма хезмәткәрләре өчен нинди социаль ярдәм күрсәтелә?

– Безнең оешмада эшчеләр өчен социаль пакет каралган. Бу аеруча күпбалалы, аз керемле гаиләләргә, лаеклы ялга китүче хезмәткәрләргә, ветераннарга кагыла. Ярты ел эчендә без хезмәткәрләрнең сәламәтлеге, ялы өчен 560 миллион сум акча тоткангыз. 130 гаилә «Ана һәм бала» программасы буенча, 460 бала сәламәтләндерү лагерьларында ял итеп кайтты. Пенсиягә китүче хезмәткәрләргә бер тапкыр пособие бирелә. Шул максатларда 6 айда гына да 150 миллион сум акча тотылды. Гаиләләрдә бала тугач та, акча бирелә. Бездә хәзерге көндә 500дән артык хатын-кыз декрет ялында утыра. Ветераннарны да онытмыйбыз. Аларга Җиңү бәйрәме саен 80 мең сум күләмендә акчалата һәм азык-төлек җыелмасы бирәбез. Эшчеләрнең торак мәсьәләсе дә кайгыртыла. Быел «Газпром» программасы буенча 11 гаилә фатир алды. Дәүләт Торак фонды программасында да катнашабыз. Хезмәт хаклары да күтәрелде. 1 гыйнвардан ел да башкарыла торган индексацияләү нигезендә, хезмәт хакы 7,5 процентка арты, ә 1 июльдән «Газпром» ГАҖ хезмәт хакына өстәмә 10 процент индексация ясый.

Боларның барысы да безнең хезмәткәрләргә тырышып эшләү өчен стимул бирә. Без аларның тырышлыгын күрәбез. Хезмәткәрләр оешмага бик рәхмәтле. Моны эшләре белән күрсәтәләр. Республика халкының иртән газда чәйнеге сызгыра, салкын көннәрдә җылыда утыра икән, димәк, бу – безнең хезмәт дигән сүз.

:: Оешма спортка зур игътибар бирә. Спортта нинди уңышларыгыз бар?

– Бездә эшләүчеләр спортны ярата. Әле күптән түгел спорт залын төзекләндердек. Анда тренажёр залы да бар, волейбол да уйнап була. Безнекеләр хоккей да уйный. Бер хезмәткәребез шахмат белән мавыга. Ул Бөтенроссия бәйгеләрендә җиңә. Волейбол ярышларында 2, 3 урыннар алдык. Быел беренче буласы килә. Әлегә Санкт-Петербургта узучы Спартакиадага әзерләнәбез. Әкренләп команда җыела инде. Безнең өчен катнашу мөһим. Спорт ярышлары кешеләрне бердәм итә. Иңне-иңгә куеп ярышкан кешеләр эштә дә бербөтен булалар. Ә бергә чакта берни комачау итми!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Кучтәнәч

Үзебезнеке яхшырак

Мәскәүнең «РОСМЭН» һәм Татарстан китап нәшрияты «Балалар энциклопедиясе» сериясендә татар телендә ун китап чыгарган.

Мәктәп яшендәге балалар өчен «Илләр һәм континентлар», «Авиация», «Бөҗәкләр», «Бизнес», «Дингезләр һәм океаннар», «Этләр», «Гаҗәеп хайваннар», «Астрономия һәм космос», «Футбол», «Тере табигать» китаплары тәрҗемә ителгән. Әлеге хезмәтләр Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән дөнья күргән. Басмаларның күпчелеге мәктәпләргә таратылган, калган өлеше сатуга чыккан.

Узган атнада китапларны Яшел Үзән районы мәгариф идарәсенә тапшырдылар.

– Мәктәпләргә балалар энциклопедияләре һәм төрле өлкәләрдә танылган татар шәхесләре сурәтләнгән плакатлар тапшыру эшен төгәлләп киләбез. Узган ел биш китап белән башлап җибәргән идек. Алар республиканың балалар бакчаларына таратылды. Быел ун төрле китапны республикада булган барлык мәктәпләргә тапшырырга булдык, – ди Татарстан китап нәшрияты директоры Илдар Сәгъдәтшин.

Аның әйтүенчә, республика мәктәпләренә 21 меңнән артык плакат һәм 40000гә якын китап тапшырылган.

– Балалар үзләрен кызыксындырган темаларга элек рус телендә генә мәгълүмат таба алган булса, бүген алар моны татарча да укый ала. Китапларны сайлау эшендә комиссия әгъзалары катнашты. Бу – Россия күләмендә иң күп таралган һәм иң яхшы кабул ителгән энциклопедияләр. Безнең күренекле шәхесләребез бик күп. Татарлар гына түгел, удмуртлар да, марилар да, чуашлар да бар. Аларга да үз халкының геройлары төшерелгән плакатларны тапшыру эшен башкарабыз.

Яшел Үзән районының 1 нче лицее татар теле укытучысы Ләйсән Миңнуллина татар телендәге энциклопедияләргә ихтыяҗ зур булуын әйтте.

– Татар теле дәресләрендә бу китапларны, һичшиксез, кулланачакбыз. Моңарчы рус телендәге китаплардан файдалана идек. Үзебезнеке булгач, бик яхшы, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

Мин кулыма китап алам

Идар Мөхәммәтҗанов

ЭЛЕКТРОН КИТАПМЫ, КӘГАЗЬ БАСМАМЫ?

Китапны гомум төшенчә дип билгеләсәк тә, гадәттә, кеше китап турында сөйләгәндә, дәреслекләрне дә, кухня нечкәлекләре, им-том исуллары һәм башка нәрсәләр турында язылганнарын да түгел, ә әдәби китапларны күз уңында тота. Аларның да кәгазь вариантларын. Безнең татарда әле электрон китапка чын китап итеп карау һич тә җитмәгән, бездә кәгазьне генә санга сугарга күнеккән халык яши. Югыйсә алга киткән чит илләрдә генә түгел, хәтта үзебезнең урыста да электрон китапларга кызыгучылар бу-лып тора, төрле премияләр бирәләр, бәйгеләр оештыралар. Электрон китап кибетләре дә, китапханәләре дә хәттин ашкан.

Ләкин безнең татарда да тора-бара электрон китаплар лаеклы урын алачактыр. Беренчедән, алар арзан, икенчедән, яңа. Яңалык монда яңа язылган килеш тәкъдим итеп дигәнне аңлата. Мин, мәсәлән, романымны бүген язып бетерәм икән, сез аның кәгазь китап булып чыкканын берничә ел көтәргә мәҗбүрсез. Ә электрон вариантын икенче көнне үк минем сайттан сатып алырга мөмкин була. Ул сезгә арзангарак та төшә. Ул, гомумән, бар яклап та отышлы: урманнарны кисеп, кәгазь ясарга кирәкми, димәк, экологиягә саклый; хәреф әргә киткән химик элементлар белән зарарламый, өстәвенә аны теләсә кайсы мизгелдә махсус җайланмадан яки телефоннан укып була. Көнен дә, төнен дә. Әлбәттә, төрле кешеләр бар. Кайберәүләр: «Мин кәгазь китапның исен яратам!» – дип әзгәләнә. Бу бәхәсле мәсьәлә инде. Махсус иснәп карагагның бар: кайберләреннән тузан исе килә, кайсыларыннан кусе печ-пече исе, бер ишләреннән… Ярый, санап тормыйм. Бары тик типографиядән яңа чыкканнарыда гына свежий буяу исе була. Яңа китапларның көтеп алсам да, мин аларның исенә бик мөкиббән китмим. Бөтен кешедә дә токсикоманлык тотылсы көчле түгелдер, күрәсең.

«Кәгазь китап яхшыракмы, әллә электронмы?» – дип сорыйлар кайчагында. Мин аптырап калам. Кечкенәдән кәгазь китап укып үскән кеше буларак, андыен да кимсетәсем килми. Анысы да әйбәт. Кулына аласың, авырлыгын тоясың. Саллы булып күренә. Минем кайбер китаплар аягына төшсә, аксатырлык бит инде, шуңа аларның эчтәлеге дә бик «весомый»дыр шикелле була. Иллюзия генә инде бу. Ләкин рәхәт иллюзия. Язучы үз иллюзияләре эчендә яши, укучы – үзенекендә.

Ә болай мин электрон китапларны ныграк үз күрәм. Бу тормыш рәвешем белән дә бәйледер. Әлегрәк, гастрольләрдә йөргән чакта сумкамның артыкы китаплар белән тулы була иде. Әйтик, бүген – Ырымбурда, иртәгә – Чиләбедә концерт. Син берничә сәгать эчендә шәһәр белән җиңелчә танышасың, шуннан репетиция ясыйсың, нәрсәләрнеңдер камилләштерәсең. Концерт ике-өч сәгатькә сузыла. Һәм вәссалам. Калган вакытың – үзеңә. Кызлар чигү чигә, бәйләм бәйли. Музыкантлар һөнәрен камиллештерә. Ә син? Конференсыде дип аталган тел бистәсе? Син китап укыйсың. Ун көнлек гастрольгә ун китап кирәк ким дигәндә. Вәт мин тәәп йөри идем. Ә электрон китаплар чыккач, бөтенләй рәхәт тормышка күчтем. Әнеккәем! Боларны бит тәнлә автобуста барганда да, иптәшләрең ут сүндерер ятканда да, теләсә кайсы вакытта укып була. Күтәренеп тә йөрисе юк. Кечкенә телефонына меңәрләгән китап сыя. Менә кайда ул җан рәхәте!

Электрон китапны чыгару да җайлырак. Мин бит инде басма китаплар чыгарып та йөргән кеше. Типографиядә эзлисең. Арзан һәм сыйфатлысын. Ә андыйлар юк. Арзан булса, сыйфаты аксый, сыйфаты булса, бәясе «каналлана». Урганарган табып чыгарасың да кибетләргә таратасың. Алырга атлыгып тормыйлар. Китап кибете булган районнарда өч-дүртне калдырып китәсең. Реклама бирәсең. Барыбер бик ярдәм итми. Үз акчаңа чыгарылган китапларны үзең катнашкан концертларда гына әйбәт сатарга мөмкин. Кайвакыт көтелмәгән уңышлар да була. Себердә, мәсәлән, «Юмор бар» дип аталган китап егермe генә данә калды. Мин боларның һәрберсен бер мең сумнан куйдым. Алсалар да бик әйбәт, алмасалар да язмыш – үземә кала. Мин ул китапларны үземә калдырырга тели идем. Бөтен юк иде. Өч концерт дәвамында шуларның барысын да алып бетерделәр. Алырга теләүчеләр соңыннан адресларын калдырып, почта аша җибәрүемне үтенеп тә йөрде. Бер мең сумга бу! Ул вакытта хәтта дөнья бестселлеры дип танылган китапларның бәясе дә ике-өч йөз сумнан артмый иде. Стивен Кингның «Мобильник» дигән китабын мин, мәсәлән, Сургутта 200 сумга сатып алдым. Шуна тиң очрак теплоходта йөзгәндә булды. Уфа – Болгар теплоходында минем белән очрашу үткәрделәр. Очрашуда катнашучылар китап сорый, ә миндә, ял итәргә генә килгән кешедә, бер-ике китап кына бар. Бүләк иттем инде кемнәргәдер. Укыганнар инде, яратканнар. Бер-берсенә сөйләгәннәр. Шуннан миңа китап сорап килүчеләр тынгы бирми башлады. Шалтыратып сөйләштем дә дусларым яңарак чыккан «Мәхәббәт яңгыры» дигән китапны Дүртөйледәге теплоход тукталышына китереп бирде. Өч-дүрт йөз данә иде бугай инде. Сатуга куйдык, ике-өч көн эчендә барысын да алып бетергәннәр. «Марат, үзең автограф куеп утырсаң, бу бер көндә бетә иде», – диделәр. Мин үзем сатмыйм да, автограф куеп утырырга да яратмыйм. Үз әсәрләрем янында мин үземне уңайсызрак хис итәм. Аларга иң әйбәт сыйфатларымны биргәнмендер дә үземдә гел тискәреләре генә калгандыр сыман тоела. Шулайрак бугай инде…

Ләкин мондый очраклар бик сирәк була. Асылда, кәгазь китапларны чыгару да, сату да бик күп кирәкмәгән эшләр, килешүләр, документ тутырулар һ.б. нәрсәләр белән бәйле. Шуңа мин китапларымның электрон вариантта чыгаруны ныграк үз итәм. Волокита дип аталган нәрсә юк монда. Законнарны бозмыйсың, салымыңны үз вакытында түлисең икән – беркем дә бәйләнми, барысы да үзеңнән тора. Язасың, яңа әсәреңне сатуга куясың, искәрмәләрен бушлай тәкъдим итәсең – теләгән кеше сатып алып укый, акчасы булмаганы ясисен бушлай чамалый. Үзеңә дә – зур стимул. Бер әсәр язган чагында икенчесе сине матди бәйлелектән азат итә. Әйтик, менә «Кайту» әсәрен сатып алучылар күп булмаса, мин «Тик син генә» дигән повестьны яза алмас идем. Язу өчен күңел тынычлыгы кирәк. Мин, гомумән, бераз патриархат кешесе бугай: сыеткычым тулы, кәшилүгем таза, хатыным елмаюлы, балаларым исәнимин, кыскасы, күңелем тыныч булмаса, бер нәрсә дә яза алмыйм. «Язучы ярлы булырга тиеш» дигән сүз ул – байлар яки саран нәширләр уйлап тапкан ялган. Әйбәт әсәр язу өчен үзеңне зур итеп тоярга кирәк. Хәерче һәм ач кеше беркайчан да зур була алмый: ярлы – акча, ач ризык өмет итә. Үзәге нык булмаган каләмчеләр өчен бу аерата куркыныч: алар хуҗасы кемгә әстерсә, шуңа әрә торган этке әйләнергә мөмкиннәр. Иҗатчының рухы нык булырга тиеш. Рухи ныклык ул тән тазалыгы белән дә, тамак туклыгы белән дә бәйле. Җан сафлыгы, әлбәттә, беренче урында тора, әмма җанның сафлыгын саклау белән җанны саклау – икесе ике мәсьәлә. Фәлсәфәгә кереп киттек бугай, бу өлешен яратмасагыз, ташлап китегез. Тик бәхәссез бер нәрсә бар: язучы язарга тиеш. Үзе теләгәнне. Фәлән хакка сатылганны түгел, ә нәкъ менә үзе теләгәнне.

Яңаны язган саен иҗат мөмкинлеге арта. Матди халәтең дә. Яңасын сатып алып, искесен бушлай укыйлар. Әсәрләреңә «искергән» саен бушлай укучылар күбәя. Аларның бик зур өлеше синең ДАИМИ УКУЧЫңа әйләнә. Мин бу сүзне һәрвакыт баш хәрефләрдән язам. Иҗатчының иң зур байлыгы ул – аның ДАИМИ УКУЧЫСЫ. Электрон китаплар белән эшләгәндә син аларны белеп, танып торасың. Минем, мәсәлән, ун меңнән артык ДАИМИ УКУЧЫМ бар. Мин шулар өчен язам. Гомум халык өчен түгел. Интернет язучыга бик зур мөмкинлекләр бирә, ул аны нәшриятлардан да, хәкүмәттән дә, көндәлекнең вак-төяк идеяләреннән дә бәйсез итә. И-и-и, аны сөйләп кенә бетерерлек түгел инде… Китаплар электрон булып кына чыксын. Аны чыгаруны да, укуын да өстенлекләре бихисап. И-и-их, электрон китап!

Менә шундый ләззәтле уйларда эреп йөргән бер вакытта электрны сүндерделәр. Озак вакытка. Телефонның да, китап уку җайланмаларының да зарядкасы беткән. Компьютер да эшләми. Электр беткәч, хәтта газны кабызып, чәй эчәрлек чут та юк икән. Мин шырпы алырга чыгып киттем, тик кибетләр эшләми: электр булмагач, аларның да эше тукталган.

> Һәм шунда мине коточкыч бер тойгы билап алды: әгәр бөтен китапларны да электронга күчереп бетерәбез икән, без көннәрнең берендә бернәрсәсез калырга мөмкинбез бит. Кешелекнең гасырлар буе тупланган гыйлеме, мәдәнияте юкка чыга дигән сүз бу.

Яраткан язучым Брэдберинның «Фаренгейт» әсәрен искә төшердем. Анда китапларны яндыралар, ә монда алар үзлегеннән юкка чыга. Шул уйлардан «Китап» романы барлыкка килде. Укыган кешеләр сүзнең нәрсә хакында баруын беләдер инде, укымаганнар надан килеш калсын: иркенләп, үз әсәрем турында сөйләп утырырга теләмим. Тик бер нәрсә бар: электрон китапларга таяну да, алардан баш тарту да – юләрлек; кәгазь китаплар белән дә хәлләр шул чама. Яңалыкка омтылган хәлдә дә искелекнең әйбәт өлешләреннән баш тартырга ярамый. Яңаның ни булып бетәрен әле беркем белми, ә «иске» дип бәяләнгәне – гасырлар сынавын узган феномен.

Ләкин сүз башындагы сорау шул килеш кала сыман: кайсы әйбәтрәк? Мин болай дип кенә җавап бирә алам: сез кайсын үз күрәсез – шул әйбәт. Сезнең өчен. Үзегез өчен әйбәт нәрсәләрне яклагыз, чөнки бөтен кеше өчен дә әйбәт әйберләр булмый, я бик сирәк була. Мин аларның икесе дә булсын дип уйлыйм. Икесе дә булсын һәм кешеләр сайлап алсын. Бездә дә сайлау ирege булырга тиештер бит инде. Хет китап өлкәсендә…

Һәм язучы буларак шулай дип тә өсти алам: минем китапларымны нинди рәвештә укыргыз артык мөһим түгел, сезнең аларны укуыгыз мөһим. Укый торган кешеләрнең булуы мөһим. Укый торган кешеләр бар икән, яза торганнары да булачак. Әдәбият дип аны кукләргә күтәреп сөйләшсәк тә, ул үзе гади генә нәрсә, әдәбият ул – язучы белән укучының әңгәмәсе. Классикларны уку – үткәннәр белән сөйләшү. Бүгенгеләрне уку – үз чорың белән аралашу. Аралашып яшик.

Марат КӘБИРОВ

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Капка төбендә утырам...

Безнең якта элек капка төбенә чыгып утыру гадәте бар иде. Өлкәннәр шулай җыелып алалар да, көтү кайтканчы, үзара гәп корып, дөнья хәлләрен сөйләшәләр, кызыклы вакыйгаларны искә төшерәләр. Тик мин көндезләрен дә чыгып утырырга ярата идем. Берүзем генә. Авылдагы күренешләрне күзәтәсең, урамнан узган кешеләрнең үзенчәлеген табарга тырышасың. Күп очракта кызыклы гына хәлләргә дә юлыгасың. Мин әле дә вакыт-вакыт шунда чыгып утырырга яратам. Хатирәләргә биреләм. Әле менә бүген дә…

Капка төбендә утырам…

Язның тәпи баскан гына чагы иде ул. Ягымлы җилләр исә. Бер ягымлы, бер усал инде алар: иркәли дә, кистереп тә ала. Тик барыбер назлы булып тоелалар, чөнки баш очында кояш балкый, җаныңны эретердәй булып нурларын сибә. Җан эри, җаннан да болайрак кар эри. Кыеклардан эре-эре тамчылар тама. Кайчандыр син көрәп өйгән көртләр кояш нурында һәм җилдә телгәләнеп, бал кәрәзенә охшабрак калган. Гөрләвекләр хасил була, алар, дәртләнеп, елгага ашыга. Менә шул беренче гөрләвекләр янында бот буе гына малай шакмаклы дәфтәр битеннән ясалган көймәчекләр агыза. Ихлас инде шундый. Каядыр бәрелеп тоткарланып калган көймәләрне саклык белән генә кузгатып җибәрә. Диңгез алласы шикелле. Борын астыннан гына ниндидер җыр суза. Аның сүзләрен дә, көен дә аңлап булмый. Җыр да түгел бугай инде ул, малайның күңел тибрәлешенең моң булып бәреп чыгуы бугай.

Мин капка төбендә утырам. Малайга нидер дип дәшәсем килсә дә, тыелып калам, аның шундый самими халәтен бозармын кебек тоела. Мин, елмая биреп, өнсез генә күзәтәм. Аның ихласлыгыннан үзем дә балкып киткәндәй булам. Күңелдә ниндидер ләззәт ургыла…

Капка төбендә утырам…

…Язның өлгереп җиткән чагы иде. Мондый мизгелне минем бер дустым «табигатьнең кыз чагы» дип билгеләргә ярата. Бәлки, ул хаклыдыр. Чынлап та, бу чорда үләннәр дә, агач яфраклары да үзгә бер яшеллек белән тирбәлә. Алардан әйтеп-аңлатып бетерә алмаслык сафлык бөркелеп тора. Бар дөньяда ниндидер җиңеллек, хәтта сулар һаваңның да берсе меңгә таркалып калган шикелле, сулыш алу җиңел, һәр сулышың җаныңны сугарган кебек. Болай дип әйтү, бәлки, дөрес тә түгелдер инде. Ләкин бөтен дөньяда искиткеч сихри халәт, күңелдә дә, тәндә дә тылсымлы җиңеллек. Иңнәреңә канат үскән кебек.

Авыл урамы буйлап туй атлары җилдерә. Гадәттә, машинада үткәрәләр инде туйны. Тик бу юлы үзенчәлеклерәк, истә калырлыграк булсын, дигәннәрдер. Матур ул чынлап та. Атлар юырта, кыңгыраулар чыңлый. Тарантаста кияү белән кәләш. Атлар артыннан бер төркем бала-чага чаба. Алар арасында теге чакта күлләвектә көймә агызып йөргән малай да бар. Ул инде бераз үсә төшкән, тик барыбер малай гына әле. Алданрак йөгергән күрше кызына кычкыра:

– Мин сине яратам! Кияүгә чыгасыңмы?

Һәм йөгергән уңайга кыз белән тәңгәлләшеп, аны кочаклап ала. Тегесе этеп җибәрә:

– Кит әле моннан… Дивана!

– «Дивана» «яратам» дигәнне аңлата, – дип көлә малай. Ул үз сүзләренә үзе дә ышана бугай, шундый ихлас, шундый бәхетле.

– Дивана! – дип кабатлый кыз аны үчекләгәндәй.

– Дивана! – дип җаваплый малай, мәхәббәттә аңлашкандай итеп. Бу сүз шундый назлы, шундый матур булып ишетелә…

Капка төбендә утырам…

Җәй иде. Кич. Җылы, ягымлы җил. Зәңгәрсу яктылык. Тик мин арыганмын, өлкән яшьтә, верандада ятам. Бер төркем яшьләр безнең капка төбенә килеп утырдылар да магнитофонмы, телефонмы кушып, җырлар акыртырга тотындылар. Җыр ул – үзең яратып тыңлаганда гына җыр, йокларга тырышып ятканда гел акыру шикелле. Ә монда минем җырларны җырлаталар. Ләкин йокларга тырышып ятканда үзең язган җырлар да артык. Мин бераз түзеп яттым да капка төбенә чыктым:

– Егетләр, бераз тавышын ябыгыз әле җырларыгызның.

Шунда теге язгы күлләвектә көймәләр агызып йөргән малай яныма килде. Хәзер егет булган инде ул, сокланып туймаслык. Янында – күрше кызы. Һәм шул егет серле генә итеп әйтеп куйды:

– Марат абый, үзегез дә тыңларлык булмагач, ни дип яздыгыз соң ул җырларны?

Берни дип тә җавап бирә алмадым. Кычкырып көлдем дә аркасыннан сөеп кереп киттем.

Капка төбендә утырам…

Иртә язларда утырам. Теге бот буе малай көймәләр агызырга чыгар кебек тоела.

Агачлар яфрак ярганда утырам. Теге малай күрше кызы артыннан йөгерер шикелле.

Җәйләр канат җәйгәндә утырам. Теге егет җырлар яңгыратыр сыман. Кайчагында үзем дә җырлар кушып куям. Үземнекеләрне. Кайдандыр тыкрык почмагыннан теге егет килеп чыгар да: «Ә-ә-ә, теге вакытта рөхсәт итмәгән идегез, хәзер үзегез акыртасызмы?» – дип елмаер кебек.

Юк.

Беркем дә.

Ә ул егет…

Узган язда табут белән кайтты. Кургаш табут белән.

Ә дөньяда берни үзгәрмәгән. Шул ук язлар, җәйләр, назлар, матурлыклар…

Ул гына юк…

Ни дип әйтим инде? Ни дип әйтсәм, кайда утырырмын икән?

Ә әлегә…

Капка төбендә утырам…

ЗАМАНЧА ЧӘЙ ҺӘМ ФӘТХУЛЛА ХӘЗРӘТНЕҢ УЯНУЫ

КАЗАНДА «ПЕЧӘН БАЗАРЫ»НЫҢ УНЫНЧЫСЫ ГӨРЛӘДЕ

Киемеңә карап каршы алалар. Заманча татар дизайнын һәм шәһәр мәдәниятен берләштергән зур чара – «Печән базары» фестивале, гадәттәгечә, Иске Татар бистәсе һәм Кабан күле яр буенда узды. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы һәм Татарстанда игълан ителгән Цифрлаштыру елы турында да онытмадылар. Традицион фестивальдә без дә булып кайттык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казанның татар җәмәгатьчелеген – дизайнерларны, рәссамнарны, музыкантларны, аш-су осталарын, галимнәрне, хореографларны, кинорежиссерларны һәм башка креатив индустрия вәкилләрен берләштергән фестиваль үзенең 10 еллыгын билгеләп үтә. Фестиваль оештыручылары сүзләренчә, ун ел дәвамында татар милли киемнәре киң даирәдә модага кергән һәм фестивальнең географиясе шактый киңәйгән.

– Фестиваль үзенең төп максатына – татар киемен популярлаштыруга иреште дип әйтергә була. Соңгы елларда татар милли киемнәре модага керде, дизайнерлар саны артты. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та татар камзулы киеп йөри башлады. Ун ел элек маркетта нибары 12 дизайнер катнашкан булса, соңгы елларда безгә 400дән артык гариза килә, – ди «Печән базары» фестиваленә нигез салучыларның берсе Гөлназ Бәдретдин.

«Печән базары» ул – беренче чиратта, милли бизәкле үзенчәлекле әйберләр сатып алу мөмкинлеге. Халык та монда иң элек шуның өчен килә. Озын-озын сузылып киткән ярминкәләр, елдагыча, фестивальнең иң популяр мәйданчыгы булды. Милли бизәкле киемнәр, яулыклар, бизәнү әйберләре, букчалар куелган ярминкә рәтләрендә бәйрәм башланганчы ук сатып алучылар күренә башлады.

– Милли бизәнү эшләнмәләре – алкалар, муенсалар, йөзекләр, беләзекләр модада хәзер. Аеруча балалар, яшь кызлар яратып ала. Аларны үзебез уйлап, дизайнын милли традицияләргә туры китереп эшлибез. Бер серияне ясау өчен бер ай вакыт китә, – ди милли бизәнү әйберләре сатучы Алия Әсләмова.

Ярминкәдә киенү-бизәнү әйберләре генә түгел, агачтан ясалган табак-савытлар, китаплар, уенчыклар, татарча интерактив әлифба һәм башка әйберләр дә бар иде. Татар мохитосыннан – татар мохите чәеннән дә авыз итеп булды.

– Без крафт чәйләр тәкъдим итәбез. Татар чәеннән – күрәгә белән мәтрүшкәне, ә мохитодан – лайм белән бөтнекне алдык. Шулай бик тәмле татар мохитосы – татар мохите чәе барлыкка килде, – дип үз эчемлеген мактады сатучылар.

Елдагыча, «Печән базары»на килүче кунаклар арасында милли киемлеләре шактый иде. Хәлимә фестивальгә Мәскәүдән килгән.

– Казанга «Печән базары» фестивале өчен махсус килдем. Бу бәйрәмне ел саен көтеп алам. Өстемдәге күлмәк, бизәнү әйберләре – барысы да татар дизайнерлары эшләнмәләре. Казанны, Татарстанны бик яратам, монда еш кайтырга тырышам, – дип сөйләде Хәлимә.

Фестиваль кунаклары, төрле темаларга багышланган лекцияләр тыңлап, фикер алышуда катнаша алды. Лекторийлар мәйданчыгында Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуның әһәмияте турында сөйләштеләр. Мәрҗани мәчете каршындагы мәйданчыкта «Заманча татар мәчете нинди булырга тиеш?» дигән сорауга җавап эзләделәр.

Татарстанның атказанган архитекторы, Кол Шәриф мәчете архитекторы Айвар Саттаров фикеренчә, заманча татар мәчетендә тормыш кайнап торырга тиеш.

– Борынгы мәчетләр дини тормышны гына күз алдында тотса, хәзерге яңа мәчетләрдә җәмәгать тормышы бара. Мин проектлаган «Ярдәм» мәчете дә заманча иҗтимагый урын санала. Анда намаз укып кына калмыйлар, иртәдән кичкә кадәр тормыш бара, – диде ул.

Кариев театры артистлары Фәтхулла хәзрәтнең, уянып, хәзерге Казан белән танышуын сурәтләгән театраль тамаша күрсәтте. Тамашачылар бер сәгать дәвамында Фәтхулла хәзрәт белән Казанның үзәк урамнары буенча йөрде.

Төрле почмакта балалар өчен мәйданчыклар эшләде. Мехенди, балчык, фетрдан эшләнмәләр ясау буенча остаханәләр, өстәл уеннары – фестивальнең нәни кунаклары өчен барысы да бар иде.

Кабан күле янындагы сәхнәдә төнгә кадәр җыр тынмады. Концертта альтернатив музыкантлар да, этнотөркемнәр дә, эстрада җырчылары да булды. Чыгыш ясаучылар арасында Alpar, Риваять, Elina һәм Искәндәр Биктаһиров, Ямьле, Abadeli һәм Фердинант Сәлахов, Лилия һәм Гөлдания Хәйруллиналар, Gauga һәм Зәйнәб Фәхретдинова, Азат Гыймадиев һәм башкалар бар иде.

Фестиваль Булат Минкинның «Берүзе» документаль фильмын, күренекле татар шәхесләре турында «Абау» анимацион видеоларын һәм Финляндия татарлары турында Рәдиф Кашапов белән Ильяс Гафаров төшергән фильмны күрсәтү белән тәгәлләнде.

Ләйсән САФИНА

РӘССАМ САНДР ПИКЛ:

«СӘНГАТЬНЕҢ ТЕЛЕ ОЗЫН ҺӘМ КҮП»

Арабыздан беребез

Һәр җирлекнең үзгә фәлсәфәле, тормышка башка күзлектән караучы берәве була инде ул. Сер түгел, без – журналистлар да андыйларны бик үз итәбез. Бәхетебез бардыр: йомышыбыз төшкән һәр җирдә очрап тора андыйлар. Буа районының Рунга авылына сәфәр чыккач та: «Безнең үз рәссамыбыз бар бит, ул сезне шаккатырачак», – дип, бик үзенчәлекле кеше янына алып киттеләр. Үзе дә, тормышы да, фәлсәфәсе дә, йорты да – әкияти, миф һәм риваятьләр дөньясы кебек.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Александр Алексеевны сәнгать дөньясында, чуашлар даирәсендә һәм авылда Сандр Пикл буларак беләләр. Гомере буе шушы авылда укытучы булып эшләгән шәхеснең хәзер өй тирәсендәге өч төрле остаханәсеннән башы чыкмый. 60 яшьтән узгач та иҗат дөньясын ташламаган, киресенчә, баш-аягы белән күбрәк тә чумгандыр әле. Символлар, риваятьләр дөньясын агач, пумала һәм буяу, таш һәм башка чималлар кулланып гәүдәләндерә торган кеше ул. Сәнгатьнең теле озын һәм күптөрле, ди бит үзе дә. Остаханәләренә керсәң, бу авылның һәм гомуми тарих турында гына түгел, чуашлар турында да тулы бер энциклопедик мәгълүмат алып чыгып китәргә мөмкин. Укытучы булуы үзенекен итә шул – Александр Алексеев ничек итеп авызына каратып сөйләргә икәнен белә.

…Алексеевларның утарына кергән һәр кешене сакчылар каршы ала. Иҗатчының үз куллары белән агачтан, бетоннан эшләнгән алар. «Сакчылар сәлам бирсә, керәсез, юк икән, кермисез. Үзенә күрә фейс-контроль бу», – дип шаяртты үзе дә. Баксаң, сыннарының бер кулы сәлам бирсә, икенчесе йодрыкка йомарланып тора, коралы да бар икән. Безгә карата хәерхаһлы булдылар тагы.

– Мин барлык эшләнмәләрне дә берүзем ясыйм. Коллектив белән башкарып чыга торган эш түгел ул. Кешеләр төрле бит. Кемдер ял итәргә, кемдер тәмәке тартып алырга ярата. Килешеп булмаска мөмкин. Ә мин үземә-үзем хуҗа кебек: эшләп чыгам икән – афәрин, юк икән – үзем гаепле. Җаваплылык – үз өстемдә. Агач белән күп еллар эшләдем. Аның белән эшләү кыенрак. Әле ул сыйфатсыз да булса… Кулым аша 300–400 еллык имәннәр дә узды. Хәзер бетонга күчтем. Мин Чабаксардагы училищеда укыдым. Идел буенда аңа тиңнәр юк иде. Нигезне шунда алдым, – ди Александр Алексеев. – Иҗат эше белән исә әти бакыйлыкка күчкәч шөгыльләнә башладым. Һәр нәрсәнең үз этәргече була. Кайгымы, шатлыкмы – кемгә ничек туры килә инде. Балалар укыттым, укучыларымны эшсез тотмадым.

Бетон белән эшләү бик җиңел эш түгел, ди танышыбыз. Тизлек кирәк. Катып китсә, сиңа кирәкле сын барлыкка килмәскә дә мөмкин. Аннан замана коралларын да кулга алырга туры килә. «Әле менә бер сынны ике көндә тиз-тиз башкарып чыктым. Кулларны төне буе көзән җыерып чыкты инде аннары», – дип көлә иҗатчы.

Ишегалдында оныклары өчен шулай ук үз куллары белән агачтан ясаган уен мәйданчыгы бар. «Диснейленд диләр бит әле, менә бит – Пикլленд. Балалар шушында шуышырга да, йөрергә дә өйрәнде, дөнья белән дә танышты», – ди әңгәмәдәш.

…Тагын бер остаханәсендә иҗатчының рәсемнәре саклана. Александр Алексеев кулы ясаган картиналарны аңлар өчен, билгеле, азмы-күпме дөньякүләм мифология, риваятьләр, тарихтан хәбәрдар булу кирәк. Күпчелегенең үзәгендә – вакыт, гомернең тиз узуы. «Вакыт ат кебек чаба, аның артыннан өлгереп булмый. Кеше дә шулай. Чаба да чаба. Ә кая чаба – билгесез», – ди рәссам. Хәер, бу сорауга җавап эзләп, бер генә картина ясалмаган инде.

…Сандр Пиклның чормадагы тагын бер остаханәсенә юл алабыз. Биредә аның шәхси тарихы, үткәне, хатирәләре яши. Шушында ук күңелен тырнап торган бер уй белән дә уртаклаша яңа танышыбыз:

– Хәзер иҗатка, ихласлыкка урын аз. Хәзер бар нәрсә дә, заманча әйтсәк, фейк, ясалма. Барысы да кысаларда. Әйтик, һәр нәрсәне иҗат өчен кулланырга була бит югыйсә. Минем остаханәләрдә дә күрдегез: нәрсә генә юк, агачы да, бетоны да, кул астына эләккән таш һәм кәкре агач-ботаклар да… Аннан, хәзер бит кыйммәтләр дә башка. Диннәр безне нәрсәгә өйрәтә? Өлкәннәргә, табигатькә хөрмәт белән кара һәм башкасы… Болар хәзер онытыла бара. Мин матди байлыкка кызыга торган кеше була белмәдем дә, түгелмен дә. Минем өчен иң мөһиме – үзем белән аңлашып яшәү. Картая барган саен авыррак та бит әле ул. Кемнедер шаккатырам дип тә тырышмыйм. Бу тормышта акча дип кенә яшәргә кирәкми. Мин мал-туарлар тотмыйм. Хатын өчен миндәй бер мал җиткән инде. Үзенчәлекле кеше инде мин. Хатыннан сорагыз әле: ничек түзәдер миңа?

…Сорадык та. Әмма ул тыйнак кына елмайды. Димәк, зарланырлыгы юк?

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6688 данә
Гомуми тираж – 15838 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 310

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+